Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре“6 нчы “Кояшкай” балалар бакчасы”
муниципаль мәктәпкәчә белес бирү учреждениясе

| | |
|---|---|
| **Рассмотрено на педагогическом совете**<br>**От «22» 09 2020 г**<br>**Протокол №1** | **Утверждаю**<br>**Заведующий МБДОУ «Детский сад № 6 «Солнышко» г. Нурлат Республики Татарстан»**<br>**__________ Н.Н.Мугинова** |
| | **Введено в действие приказом заведующего МБДОУ «Детский сад № 6 «Солнышко» г. Нурлат Республики Татарстан»**<br>**От « 23» 09 2020 г № 94** |

# Икенче кечкенәләр төркеменең (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)
# 2020-2021 нче уку елына
# эш программасы


Төзүче тәрбиячеләр:
Ибляминова Э.Я.
Алексеева А.М.


Нурлат шәһәре
2020 ел

## Эчтәлек

**1.Максатчан бүлек.**.......................................................................................................1

1.1. Аңлатмалы язу..........................................................................................................2.
1.2.Программаны эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен кирәкле характеристикалар..............................4
1.3. 3-4 яшьлек балаларның яшь үзенчәлекләре.......................................................................5
1.4. Төркемнең социаль паспорт .........................................................................................5
1.5. Төркемнең өстенлекле юнәлеш эшчәнлеге.......................................................................5
**2.Эчтәлекле бүлек** ..........................................................................................................6
2.1. Икенче кечкенәләр төркемендә оештырылган эшчәнлектә белем бирү өлкәләрен тасвирлау ...........................................................................................................................6
1.“Социаль-коммуникатив үсеш”.........................................................................................6
2. “Танып белү үсеше”........................................................................................................13
3.“Сөйләм үсеше................................................................................................................ 19
4.“Сәгати эстетик үсеш”.....................................................................................................25
5. “Физик үсеш”..................................................................................................................48
2.2. Комплеслы тематик план ..............................................................................................
2.3. Икенче кечкенәләр төркемендә оештырылган эшчәнлектә вариатив формаларны куллану ..........................................................................................................................54
2.4. Әти-әниләр белән эш ......................................................................................................54
**3.Оештыру бүлеге**
3.1. Материаль-техник база......................................................................................................57
3.2. Методик кулланмалар.......................................................................................................59
3.3. Предметлы үстерешле мохит..............................................................................................60
3.4. Көндәлек режим................................................................................................................61
3.5. Атналык оештырылган белем бирү эшчәнлеге...................................................................63
3.6.Сәламатләндерү эшчәнлеге.................................................................................................64
3.7Үзенчәлекле вакыйгалар,бәйрәмнәр,мероприятияләр..........................................................65

## 1.Максатчан бүлек

### 1.1Аңлатма язуы.

Бу программа “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына Федераль дәүләт таләпләре”нә нигезләнеп, Н.Е.Вераксы, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге ”Туганнан мәктәпкә кадәр”төп гомуми мәктәпкәчә яшьтә белем бирү программасына,балалар бакчасының еллык эш планына таянып төзелде.

Программаның төп бурычлары-мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы кыйммәтле яшәеше өчен уңай шартлар тудыру , шәхес культурасының нигезле җирлеген формалаштыру, шәхси һәм яшь үзенчәлекләренә яраклаштырып, физик һәм психик сыйфатларны төрле яклап үстерү, баланы хәзерге җәмгыятьтә яшәргә, мәктәптә укырга әзерләү, мәктәпкәчә яшьтәге баланың куркынычсыз яшәү рәвешен булдыру. Бу максатлар бала эшчәнлегенең ( уен, аралашу, хезмәт, танып-белү, иҗади, уку) төрле процессларында тормышка ашырыла.

Бүген җәмгыятьтә катлаулы социаль-экономик процесслар бара, белем бирүнең кыйммәтләре һәм максаты тамырдан үзгәрә. Балаларга белем бирүнең бөтен өлкәләрендә дә актив, иҗади, үзгәртергә әзер торучы шәхес тәрбияләү таныла. Балаларның шәхси һәм социаль мөнәсәбәт позициясен күздә тотып, аларны мәктәпкә әзерләүдән күчү, мәктәпкәчә белем бирү нәтиҗәләренең күзаллавын үзгәртергә булыша. Нәтиҗәлелек: мәктәпкәчә яшьтәге балаларда кызыксынучанлык, активлык, мөстәкыйльлек сыйфатларын формалаштыра; ялгышларны уңышсызлыкларны җиңеп чыгарга әзерлек, яңа белем алырга, стандарт булмаган ситуацияләрдән чыгу юлын эзләргә омтылыш тудыра; үзе сайлаган эшкә җаваплылык, командада эшли белү, үзенә, башкаларга, җәмгыятькә, әйләнә-тирәгә ихтирамлы караш, кайгыртучанлык тәрбияли. Болар барысы да баланы мәктәпкә әзерләп кенә калмый, ә хәзерге җәмгыятьтә уңышлы мөстәкыйль эшләү өчен нигез булып тора. Билгеле, мондый нәтиҗәләргә ирешү өлкәннәрнең фикер йөртүендәге үзгәртеп корулар белән бәйле, педагоглар һәм ата-аналар үзгәртеп коруда үзләре башлап йөрергә тиеш. Шунлыктан, программа педагог-бала-ата-ана мөнәсәбәтенә ориетлаштырылган.

### 1.2 Программаны эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен кирәкле характеристикалар

Без тирән үзгәрешләр һәм икътисади үзгәртеп корулар чорында яшибез.

Белем бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең эше дә көннән-көн яңара, матур традицияләргә байый.Педагоглар яшь буынны тәрбияләүдә яңа чаралар, белем бирүнең нәтиҗәле методларын эзлиләр, тәрбия эшендә халкыбызның күркәм традицияләренә, педагогик тәҗрибәсенә ныграк таяналар. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә зур игътибар бирелә

**Программаны тормышка ашыру срогы - 1 ел (2018-2019 уку елы)**

**Эш программасы түбәндәге норматив документларга таянып төзелде:**
*Белем бир үөлкәсендә федераль дәрәҗәдә:*
1.Федеральный закон от 29.12.2012 №273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации»

.2.Приказ МОиН РФ от 17.10.2013 №1155 «Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования».

- «Татарстан Республикасыдәүләттелләреһәм Татарстан Республикасында башка телләртурында Татарстан Республикасы Законы» 08.07.1992 № 1560 - XII
- “Порядком организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – образовательным программам дошкольного образования» (приказ Министерства образования и науки РФ от 30 августа 2013 года №26, 2.4. 3049-13)
- Постановление Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 15.05.2013 г. №26 г. Москва «Об утверждении СанПиН 2.4.1.3049-13 «Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации режима работы дошкольных образовательных организаций».
- Законом РТ «Об образовании» от 22 июля 2013 года № 68 – ЗРТ
- Примерной основной образовательной программой дошкольного образования- Научный руководитель проекта А.Г.Асмолов. Одобренной решением федерального учебного- методического объединение по общему образованию от 20 мая 2015 г. №2/15-М. издательство «Национальное обраование», 2015г.
- Общеобразовательной программой дошкольного образоания «От рождения до школы» Под.ред. Н.Е. Вераксы, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой.- М:МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2014г

*Белембирүөлкәсендәрегиональдәрәҗәдә:*

- Балалар бакчасында Региональ белем бирү программмасы “Сөенеч- Радость Познание”/Р.К.Шәехова Казан: Мәгариф вакыт, 2016 ел.

*С документами локального уровня:җирледәрәҗәдә:*

– Уставом МБДОУ;
– Лицензией на право ведения образовательной деятельности;
– Годовым планом работы;
– Учебным планом;
– Календарным учебным планом- графиком ;

**Программа түбәндәге бурычларны куя:**

1. Балаларның сәламәтлеген саклау, аларның физик һәм психик үсешен тәэмин итү.
2. Тәрбия-белем бирү эшен гуманлаштыру.
3. Халык традицияләренә, милли гореф гадәтләргә нигезләнеп балаларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.
4. Балаларның сәләтләрен ачу, юнәлеш бирү һәм үстерү өчен шартлар тудырып, нык белемле, зирәк акыллы шәхес формалаштыру.
5. Балалар иҗаты нәтиҗәләренә хөрмәт белән карау.
6. Балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә дәвамчанлыкны саклау.

Бу бурыч-максатларны тормышка ашыру һәр тәрбиянең педагогик осталыгыннан аның мәдәниятлелегеннән, әхлаклылыгыннан, максатчан эшләвеннән һәм иң мөһиме балаларны яратуыннан тора. Тәрбияче балаларның сәламәтлеген, тәрбиялелеген, әхлаклылыгын кайгыртып әти-әниләр белән берлектә һәр баланы бәхетле итәргә тиеш.

## 1.3. 3-4 Яшьлек балалар үсешенең яшь үзенчәлекләре

Бала үсешендә мәктәпкәчә яшь чоры күп төрле һәм дия намикалы булуы белән аерылып тора. Әлеге чор дәвамында төрле юнәлешләр буенча сизелерлек үзгәрешләр барлыкка килә. Уен, рәсем, төзү кебек эшчәнлек төрләре камилләшә. Безнең күз алдында 3—4 ел дәвамында балаларның игътибарры, хәтере, фикерләве, күзаллавы, сөйләме көчле үсеш

ала. Гади җөмләләр катлаулылары белән алышына һәм кызыклы кечкенә хикәяләргә әверелә. Бу яшьтә баланың дуслары барлыкка килә башлый, ул һәм зурлар белән теләп аралаша, үз тәртибен көйли. Дөнья турында күзаллавы киңәя һәм «нигә?», «ни өчен?» сораулары җавап таләп итә. Мәктәпкәчә яшь чорының башы 3 яшьтәге кискен үзгәреш белән туры килә. Иртә яшьтә үсеш һәм тәрбия дөрес оештырылган булса, баланың 3—4 яшьтә буе 90—100 смга җитә, гәүдә авырлыгы якынча 13—16 кг була. Аның җитезлеге арта, тизрәк йөгерә, яхшырак сикерә, ыргыткан тупны ике кулы белән тотып ала. Әле 2 яшьтә ул бу хәрәкәтләрнең берсен дә эшли белми иде! 3—4 яшьтә балалар физик яктан көчлерәк, мөстәкыйльрәк. Физик тәрбия акыл тәрбиясе белән бәйләнештә алып барыла. Бу яшьтә акыл, эстетик, әхлак, физик үсеш югары темп ала. Мәктәпкәчә яшьтәге бала әйләнә-тирә дөньяны танып белә, күзәткән вакыйгаларны, күренешләрне аңларга тырыша. Дөрес оештырылган педагогик процесс нәтиҗәсендә балалар төрле төшенчәләрне үзләштерәләр, нәтиҗәләр чыгаралар, гомумиләштерәләр. Балаларның кызыксынучанлыгы, яхшы хәтере аңа күп информация тупларга ярдәм итә. Кызыксынучанлык баланы эзләнү эшчәнлегенә (Н.Н.Поддьяков), зурларга сораулар белән мөрәҗәгать итәргә стимуллаштыра. Сораулар характеры буенча баланың үсеш дәрәҗәсен билгеләргә була. 3—4 яшьлек баланың аралашуы гаилә белән генә чикләнми. Зурлар бала өчен гаилә әгъзасы гына түгел, ә билгеле иҗтимагый функция үтәүче булып та тора. Баланың шундый ук функция үтәргә теләве аның реаль мөмкинлекләре белән каршылыкка очрый. Әлеге каршылык» мәктәпкәчә яшьтә әйдәүче эшчәнлек — уен аша чишелә.

Уенның төп үзенчәлеге, аның шартлы рәвештә булуында. Кече мәктәпкәчә яшьтәге бала уенының төп эчтәлеген уенчыклар һәм предметны алмаштыра торган җиһазлар тәшкил итә. Бу яшьтә балаларның уены озак вакытка сузылмый. Кече мәктәпкәчә яшьтәге балалар уенда берике роль һәм гади сю-жетлар белән чикләнәләр. Кагыйдәле уеннар әле формалаша гына башлый.

3-4 яшьлек балаларның эшчәнлеге катлаулана һәм төрләләнә: алар уку һәм хезмәт биремнәрен уеннар аера башлыйлар. Уен һәм шөгыль нәтиҗәсендә психик процесслар (хәтер, фикерләү, игътибар, күзаллау) үсеш ала, балаларның яңа ихтыяҗлары һәм мәнфәгатьләре барлыкка килә.

Информатив, катлаулы һәм күләмле күрсәткеч булып акыл үсеше тора. Киң мәгънәдә акыл үсеше төп танып белү про-цессы үсеше буларак аңлатыла. Тар мәгънәдә — акыл сәләте үсеше. Акыл сәләте үсеше баланың әйләнә-тирәдә ориентирлашу ысулларын гомумиләштерүне күз алдында тота.

3-4 яшьлек балалар үсешендә сәнгать эшчәнлеге мөһим урын алып тора. Әлеге эшчәнлек баланың предмет турындагы күзаллауларына бәйле. Бу яшьтә күзаллаулар формалаша гына башлый. График образлар ярлы. Кайбер балаларның рәсемнәрендә детальләр төшеп кала, ә икенчеләре киресенчә, җентекләп ясый. Балалар рәсемнәрдә төрле төсләр куллана башлый. Кул моторикасын үстерү өчен əвәләү, бармаклар гимнастикасы зур әһәмияткә ия. Кече мәктәпкәчә яшьтәге балалар зурлар җитәкчелегендә гади предметлар әвәләргә сәләтле. Кисеп ябыштыруның (аппликация) кабул итү үсешенә уңай йогынты ясавы билгеле. Бу яшьтә кисеп ябыштыруның иң гади төрләрен башкаралар.

Кече мәктәпкәчә яшьтә балаларның төзү эшчәнлеге, үрнәк буенча һәм уйлап чыгарылган катлаулы булмаган төзелешләр белән чикләнә.

Әлеге яшьтә аерым эшчәнлекләр үсеш ала. Балалар башлангыч эталоннарны (кабул итүнең индивидуаль берәмлекләре) кулланудан сенсор эталоннарга (кабул итүнең эшкәртелгән чаралары) күчәләр. Кече мәктәпкәчә яшь ахырына балалар предметларның һәм төсләрнең биштән алып җиде төренә кадәр аералар, предметларны зурлыгы буенча дифференциациялиләр, балалар бакчасының төркем бүлмәсе, белем бирү процессын оештырганада, бөтен балалар бакчасы бинасы пространствосында ориентирлашалар.

Хәтер һәм игътибар үсеш ала. Зурлар үтенече буенча балалар 3-4 сүз һәм 5-6 предмет исемен хәтерләрендә калдыралар. Кече мәктәпкәчә яшь ахырына алар яраткан әсәрләрдән өзекләрне истә калдырырга сәләтле. Күрсәтмә-хәрәкәт фикерләве үсеше дәвам итә. Шуның белән беррәттән, кайбер очракларда, теләгән нәтиҗәләрне исәпкә алып, максатчан үрнәк нигезендә ситуация үзгәрә. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар предметлар арасындагы кайбер яшерен бәйләнешне билгеләргә сәләтле. Кече мәктәпкәчә яшьтә күзаллау үсеш ала һәм ул бигрәк тә уенда чагылыш таба. Балалар арасындагы үзара мөнәсәбәт нормалар һәм кагыйдәләр белән билгеләнә. Максатчан тәэсир итү нәтиҗәсендә, алар үзләренең һәм башка балаларның эшләрен бәяләү өчен ни-гез булган, чагыштырмача зур күләмдә нормаларны үзләштерә алалар. Балалар арасындагы үзара мөнәсәбәт бигрәк тә уем эшчәнлегендә ачык чагыла. Шулай ук бу яшьтә сайлауга корылган үзара мөнәсәбәт тә күзәтелә.

### 1.4.Төркемнең социаль паспорты

Икенче кечкенәләр төркеменә 3 яшьтән 4 яшькә кадәр26 бала йөри.. 12 малай, 14 кыз..Национал ь состав: 18 татар, 5 рус, 3 чуваш

### 1.5.Төркемнең өстенлекле юнәлеш эшчәнлеге.

1.Балаларда дөньяви эстетик үсешне, табигатьнең матурлыгын чынбарлыкта күрә, аңлый белүне формалаштырдык.
2.Балаларның һәм ата-аналарның рухи-әхлакый һәм иҗади сәләтләренең дәрәҗәсен күтәрдек.
Икенче кечкенәләр төркемендә Программаны тормышка ашыруның төп юнәлеше – балаларның танып белү, сөйләм, социаль-коммуникатив, сәнгати-нәфасәти, физик үсешенә шартлар тудыру. Төркемдә белем бирү процессы комплекслы һәм яңа буынның парциаль программалары нигезендә башкарыла. Программаның беренче планына белем бирүнең үстерешле функциясе куела. Программа балага гуманлы-шәхсипозициясендә төзелгән һәм аның һәрьяклы үсешенә, рухи һәм гомумкешелек кыйммәтләре, компетенциясе, сәләте формалашуга юнәлгән. Программада балаларга белем бирүдә каты регламентация юк. Программада уен эшчәнлеге аерым урын алып тора, баланың туганнан алып мәктәпкәчә чорына кадәр белем һәм тәрбия бирү процессы комплекслы бирелгән. Программаның төп максаты – күчүчәнлек принципын тормышка ашыру һәм белем бирү системасы концепциясенә яраклаштырып мәктәпкәчә яшьтәге балаларга тәрбия һәм белем бирү.

## 2. Эчтәлекле бүлек

### 2.1 Икенче кечкенәләр ттөркемендә оештырылга эшчәнлектә белем бирү өлкәсен тасвирлау

**2.1 Социаль- коммуникатив үсеш**

Балаларны кешеләр белән аралашу әдәбенә өйрәтү: тәрбиячегә һәм тәрбияче ярдәмчесенә, музыка җитәкчесенә исеме,әтисенең исеме белән мө- рәҗәгать итәргә; зурлар һәм иптәшләре белән исәнләшергә, саубуллашырга гадәтләндерү.

Күрсәткән ярдәме һәм игътибары өчен өлкәннәргә, яшьтәшләренә рәхмәт әйтергә,үтенечен ачык итеп,**зинһар**сүзен кушып белдерергә күнектерү.

Чишенү,юыну,йокы бүлмәләрендә, ашханәдә һәм урамда үз-үзеңне дөрес тотуның иң гади кагыйдәләрен үтәргә: үзеңне тыныч тотарга, тавышланмас- ка, тирә-юньдәгеләргә комачауламаска гадәтләндерү.

Балаларны үзара дус яшәргә, бер-берсенә ярдәм итешергә, уенчык һәм китаплардан уртак файдаланырга, кечкенәләргә карата кайгыртучанлык күрсәтергә, дөресен сөйләргә, алдамаска өйрәтү. Үзара ачык йөз белән, ягым- лы сөйләшергә гадәтләндерү. Иптәшләренә инсафлы, ягымлы, җылы мөнәсә- бәттә булырга күнектерү.

**Танып белү үсеше.**

Балаларны балалар бакчасында ориентлашырга өйрәтү, үз туган җире, шәһәре турында белемнәрен үстерү.

Балаларны өлкәннәр( шәфкатьтуташы, пешекче) хезмәте белән таныштыру- руны дәвам итү, аларның игътибарын бу хезмәт кешеләренең эшенә һәм эшнең нәтиҗәсенә юнәлтү.Өлкәннәр хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.

Предметларны кулланылышы, төсе, формасы, материалы буенча чагыш- тыру һәм төркемләргә өйрәтү. Гомумиләштерүче сүзләрнең (уенчык,кием- салым, аяк киеме, җиһаз, савыт-саба) мәгънәсен аңлату.

Балаларны агачның кәүсәсен, ботакларын, яфракларын; үләнчел үсемлек-ләрнең сабак, яфрак, чәчәкләрен таный һәм әйтеп бирергә өйрәтү.

4-5 төрле яшелчә һәм җиләк- җимешне танырга өйрәтү, йорт хайваннары һәм кыргый хайваннар турында күзаллау булдыру. Җир-су хайваннары белән таныштыру.Табигатьтә аларның әһәмиятен аңлату.

Балаларны төзелгән корылмаларга гади анализ ясарга өйрәтү,конструктор- лык осталыкларын камилләштерү. Корылманың өлешләрен зурлыклары бу- енча (зур- кечкенә, озын- кыска, биек- тәбәнәк, тар- киң) аера һәм әйтеп бирә белергә өйрәтү. Балаларның үзләре уйлаганча төзү теләген үстерү.

Балаларның логик фикерләвен,игътибарын һәм хәтерләрен үстерү.

Күплек, сан, зурлык, форма,тирәлек һәм вакыт төшенчәләре турында белем бирү, санау, исәпләү, үлчәү,төзү күнекмәләрен формалаштыру; мате- матик мәсьәләләр чишкәндә ихтыяр көче, мөстәкыйльлек тәрбияләү.

**Сөйләм үсеше**

Балаларның тирә- юнь турындагы белемнәре арту нәтиҗәсендә аларның сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру. Әйберләрнең өлеш-кисәкләрен атарга, аларның формаларын һәм төсләрен, нәрсәдән ясалуын әйтә белергә өйрәтү.

Гомумиләштерүче сүзләрнең мәгънәсен аңлый белергә өйрәтү.

Тирә- юньдәге әйберләрнең исемнәрен куллануны активлаштыру. Сөйләшкәндә таныш әйберләрнең исемен, сыйфатын, хәрәкәт урынын аңла- та торган сүзләрне куллана белү күнекмәләре бирү.

Балаларның артикуляция аппаратын камилләштерү һәм фонематик ишетү сәләтен үстерү юнәлешендә эзлекле эш алып бару.

Авазларны, сүзләрне һәм гади җөмләләрне ашыкмыйча, ачык һәм аңлаеш- лы итеп әйтергә өйрәтү.

Балаларның җөмләләрне дөрес итеп төзи белү күнекмәләрен арттыру.

Хайваннарның, кош-кортларның һәм аларның балаларының атамаларын берлек санда, күплек кушымчалары ялгап дөрес итеп әйтергә өйрәтү.

Зурлар һәм иптәшләре белән иркен аралашырга; төрле эшчәнлекләрдә диалогик, монологик сөйләм формаларын кулланырга өйрәтү.

Рәсемнәр, иллюстрацияләр, уенчыклар буенча тәрбияче биргән сорауларга җавап кайтарырга өйрәтү.

Балаларны хикәя төзеп сөйли белергә хәзерләү: күргән уенчыклар яки рә- семнәр турында 3-4 җөмләдән торган хикәяләрне тәрбияче артыннан кабатлау. Таныш әкиятләрнең кайбер өлешләрен рольләргә бүлеп сөйләргә өйрәтү.

Әдәби сөйләмне үстерү.

**Сәнгать-эстетик үсеше.**

Балаларда сынлы сәнгать шөгыльләренә кызыксыну тәрбияләү. Рәсем, әвәләү, кисеп ябыштыру шөгыльләрендә әйләнә-тирәдәге гади генә предмет- ларны һәм күренешләрне образлы итеп сурәтләргә, рәсемнәрне кәгазь битенә урнаштырырга өйрәтү.Кисеп ябыштыруның иң гади күнекмәләрен бирү.

Балаларны предметларның формасы, зурлыгы, төзелеше, төсе белән таныштыруны дәвам итү.

Рәсемдә, иллюстрацияләрдә, халык уенчыкларында төсләрнең матурлы- гын, ачыклыгын күрә белергә өйрәтү.

Кулга каләм, пумала тотарга өйрәтүне дәвам итү. Төсләрне белүләрен ныгыту. Балаларны яңа төсмерләр ( алсу, сыек зәңгәр,соры) белән таныш- тыру. Предметка туры килгән төсне сайлап алырга өйрәтү.

Штрих,буяуларны салмак төшерергә, әйләнә-тирә чынбарлыктагы күре- нешләрне һәм предметларны сурәтләргә өйрәтү.

Төрле юнәлештәге туры, авыш, озын, кыска сызыклар үткәрергә, аларны кисештерергә, түгәрәк формалы предметларны һәм күренешләрне сурәтләр- гә,формасы турыпочмаклы предметларны, түгәрәк һәм турыпочмаклы фор- маларны бергә катнаштырып әйләнә-тирә чынбарлыктагы предмет һәм күре- нешләрне сурәтләргә өйрәтү.

Әвәләү белән кызыксыну тәрбияләү. Балчыкның үзлекләре белән таныш- тыруны дәвам итү. Балаларны катлаулы булмаган әйберләр:шар, каләм,та- бак, тәлинкә, клиндер ясарга өйрәтү.

Бер үк төрле һәм төрле формадагы берничә өлештән торган гадирәк пред- метларны бер өлешен икенчесенә тыгыз итеп кысып ябыштыру юлы белән әвәләргә өйрәтү.

Балаларда ябыштыру шөгыленә кызыксыну тәрбияләү.Тәрбияче әзерләп биргән 2-3 кисәктән торган предметларның сурәтләрен кәгазь битенә тезеп чыгарга һәм ябыштырырга өйрәтү. Җилем белән эшләү күнекмәләрен үстерү. Геометрик элементлардан буй сызыкта, квадратта, турыпочмаклыкта, түгә- рәктә төсе, формасы, зурлыгы буенча чиратлаштырып бизәк төзү күнекмәлә- ре бирү.

**Физик үсеше**

Физик культура һәм сәламәтләндерү эшләре. Балаларның сәламәтлеген ныгыту өстендә эшләүне дәвам итү: организмны чыныктыру, төп хәрәкәтләрне камилләштерү, гәүдәне төз тоту гадәтен ныгыту. Мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтле, спорт уеннары оештырырга, физик күнегүләр башкарырга, йөзәргә өйрәтү. Гимнастика эскәмисенең тар рейкасы һәм бау буенча атлап, баш өстенә ком тутырылган кечкенә капчык куеп тигезлекне саклау күнегүләре ясау. Гадәти йөгерү, аяк очларында тезләрне югары күтәреп каршылыкларны җиңеп йөгерү, шуышу, үрмәләүне камилләштерү. Предметларны еракка ыргыту, тупны

чөю һәм тотып алу хәрәкәтләрен, кул чукларын, иңбаш, арка мускулларын ныгыту, умыртка баганасының сыгылмалылыгын арттыру күнегүләре ясау, спорт уеннары уйнау.

**2.2Белем өлкәләре буенча комплекслы-тематик план**

| Вакыты | | Бүлекләр | Бурычлар | Үткәрелгән чаралар |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь | 1 | Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы! | Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы!1) сорауларга җавап бирергә теләк уяту; сюжетны чагылдыра торган уеннарда катнашу теләге тәр бияләү. | “Белем көне”- тәрбиячеләр һәм эти – әниләр катнашында. |
| | 2 | Көз | балаларның көз, табигать тәге көзге үзгәрешләр, җиләк-җимешләр (алма, анның билгеләре) турында күзаллауларын баету нигезендә сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру, тиңдәш кисәкләр кергән җөмләләр төзергә өйрә түне дәвам итү; | “Көзге уңыш”- эти – әниләр һәм балалрның иҗадый эш выстовкасы. |
| | 3 | Көз | балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, сенсорик күнекмәләрен, артикуляция аппаратын үстерү; | “Көз” бәйрәме |
| | 4 | Көз | күмәк эшләүгә тарту, сорауларга җавап бирү теләге тәр бияләү. | Көзге спорт уеннары |
| Октябрь | 1 | Мин һәм минем гаиләм | балаларның гаилә һәм гаи лә әгъзалары турындагы белемнәрен баетуны дәвам итү; | “Минем гаиләм”<br>Гаилә агачы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2 | Мин һәм минем гаиләм | 2) балаларның игътибарын, хәтерен, аңга алуларын үстерү;<br>3) олылар белән ирекле ара лашу күнекмәләре; гаиләгә һәм гаилә әгъзаларына карата игътибарлылык, кайгыртучанлык тәрбияләү. | Спорт бәйрәме |
| | 3 | Минем йортым, минем шәһәрем | балаларны туган шәһәр, аның исеме (Нурлат), шәһәрдә чыга торган “кара алтын”, шикәр заводы белән таныштыру, юл йөрү кагыйдәләре турында элементлар белемнәр бирү | “Туган шәһәрем” рәсем күргәзмәсе |
| | 4 | Минем йортым, минем шәһәрем | аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен үстерү; сүзләрне, кыска фразаларны ачык әйтә белүләренә ирешү; нефтьнең чыгышы белән кызыксынуларын үстерү; | “Туган ягым”- презентация карау |
| | 5 | Минем йортым, минем шәһәрем | туган шәһәр, нефтьче эшчеләре, аларның хезмште белән горурлану хисе тәрбияләү | Сюжетлы рольле уеннар |
| Ноябрь | 1 | Минем йортым, минем шәһәрем | Минем йортым | Балаларның рәсем күргәзмәсе |
| | 2 | Минем йортым, минем шәһәрем | Минем шәһәрем | Балаларның рәсем күргәзмәсе |
| | 3 | Әниләр бәйрәме | Балаларга бу бәйрәм турында мәгълүмат бирү. Балаларда әниләр көненә кызыксыну уяту. | “Әнием – кадерлем” әдәби – музыкаль кичә. |
| | 4 | Әниләр бәйрәме | Әниләр белән бердәм эшләр башкару. Якын кешеләренә карата хөрмәт, ярату хисләре тәрбияләү. Әниләргә бәйрәм хөрмәтенә бүләкләр ясау, шигырьләр, җырлар өйрәнү. | “Әниемнең уңган куллары”- әниләр белән поделкалар ясау |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Декабрь | 1 | Яңа ел бәйрәме | сөйләмдә бәйлек сүзләрне (эчендә, артында, астында, өстә, өстендә) кулланырга, «кайда?, «кая?» сорауларына җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итү; | Дидактик уен “Кар бертеген җый” |
| | 2 | Яңа ел бәйрәме | игътибарны, тәрбияченең күрсәтмәләре буенча эшләү күнекмәләрен үстерү; | Кар бертекләре ясау |
| | 3 | Яңа ел бәйрәме | җәнлекләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләү.Җәнлекләр яңа ел бәйрәмендә. | “Кышкы урман” Рәсем күргәзмәс |
| | 4 | Яңа ел бәйрәме | Яңа ел бәйрәме | “Кыш бабайда кунакта” әти әниләр катнашында әдәби – музыкаль кичә |
| Январь | 1 | Кыш | 1) кышкы киемнең бил геләнешен, төсен, аерым детальләрен, материалын атап, аны сурәтләргә; исемне сыйфат белән бәйләп, сорауларга тулы җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү; | «Кыш» - әти – әниләрнең һәм балаларның рәсем күргәзмәсе |
| | 2 | Кыш | тукыма, мех, йомшак, җылы, шома, ак, яшел, зәңгәр сүзләре хисабына сүзлекләрен активлаштыру, конкрет-образлы фикерләүләрен, игътибарларын, күрү хәтерләрен үстерү; | Курчакларга кышкы киемнәр |
| | 3 | Кыш | киемнәргә карата сакчыл караш тәрбияләү.<br><br>1) балаларның кыш турында күзаллауларын киңәйтү; кар, аның билгеләре белән таныштыруны дәвам итү; сөйләмдә сыйфатларны дөрес куллана белүләренә ирешү; 2) балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, рәсем ясауга кызыксынуларын, пространствода ориентла шуларын, сөйләм сулышын үстерү; 3) башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. | “Кыш” шигырлщр уку |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 4 | Мин үзем өчен иң кадерле кеше | Балаларга кешенең үсеше турында күзаллаулар бирү. Төрле яшьтәге һәм җенестәге кешеләрне аерырга өйрәтү. Сөйләмнәрен, логик фикерләүләрен ныгыу. | Дидактик уен “Мин кем” |
| Февраль | 1 | Ватанны саклаучы лар көне | 1) балаларны Ватанны саклаучылар коне белән таныштыру; 3 | “Әти белән кечле мин” әтиләр катнашында кич |
| | 2 | Ватанны саклаучы лар көне | 2) балаларның игътибарын, аңга алуларын; диалогик, монологик сөйләмнәрен үстерү; | Рәсемнәр ясау |
| | 3 | Ватанны саклаучы лар көне | Ватанны саклаучылар көне | Әтиләр белән әдәби музыкалж кичә. |
| | 4 | Ватанны саклаучы лар көне | балаларда Туган илгә мәхәббәт, малайларда көчле, кыю булырга омтылыш тәрбияләү. | Спорт уеннары |
| Март | 1 | Сигезенче Март | 1) балаларның әниләр бәйрәме турындагы белемнәрен киңәйтү, [ә] авазын ачык итеп әйтүләрен камилләштерү; әңгәмәдә кат нашуга тарту; 2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, диалогик сөйләм формасын үстерү; 3) балаларда әниләргә мәхәббәт һәм аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. | “8 Март – хатын – кызлар бәйрәме” әниләр катнашында әдәби- музыкаль кичә. |
| | 2 | Халык җәүһәрләре | балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга, сюжетның эзлеклелеген күзәтә белергә өйрәтү; | татар халык әиятләре буенча лэпбуклар ясау. |
| | 3 | Халык җәүһәрләре | Тычкан-Чыелдык, бака- Бакылдык, куян- Куркаккай, төлке-Хәйләбай, бүре- Сорыколак, аю- Камытаяк сүзтезмәләре хисабына балаларның сүзлеген баету, активлаштыру; игътибарны, ишетү, күрү хәтерен үстерү; | Әкиятләр буенча сәяхәт |
| | 4 | Халык җәүһәрләре | халык иҗатына кызыксыну тәрбияләү | Өстәл уеннары |
| Апр | 1 | Яз | язгы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре турында күзаллауларын киңәйтү; | “Яз”- балалрның рәсем күргзмәс |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| е<br>л<br>ь | 2 | Яз | язгы табигатьнең характерлап тәрбияче белән бергә кечкенә хикәя (2-3 җөмлә) төзергә өйрәнү. | Презентация карау |
| | 3 | Яз | балаларда хайваннар тормышы белән кызыксыну тәрбияләү | Рәсемнәр ясау |
| | 4 | Яз | Балаларда язын кошлар тормышы белән таныштыру. Сакчыл караш тәрбияләү | Әтиләр белән җимлекләр ясау |
| | 5 | Без әкият яратабыз | Балаларны әкиятләрне сәхнәләштерергә өйрәтү. Театр төрләре белән таныштыру. Өйрәнгән әкиятләре турында күзаллау формалаштыру. Халык әкиятләре белән танышуны дәвам итү. Әкият геройларының исемнәрен ныгыту. Халык авыз иҗатына карата кызыксыну уяту, хөрмәтлелек тәрбияләү | Татар халык әкиятләре буенча өстәл театры карау |
| М<br>а<br>й | 1 | Җиңү бәйрәме | 1) балаларның Җиңү көне турында күзаллауларын формалаштыруны, | “Җиңү көне”-Әдәби кичә |
| | 2 | Хәрби һөнәрләр | хәрби һөнәрләр, аларның баш кием-нәре белән таныштыруны дәвам итү, сугышчыларның батырлыгы турында сөйләү, хәрби техника турында бе-лемнәрен киңәйтү; | Өстәл уеннары |
| | 3 | Җәй | табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, билгеле бер ситуациягә туры килгән фигыльләрне сөйләмдә куллануларын активлаштыру; | “Җәй” – балалрның иҗадый эш күргәзмәсе. |
| | 4 | Ямле җәй | балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, уңай хис- кичерешләрен, аңга алуларын үстерү; 3) табигатькә сакчыл караш тәрбияләү | Тирә юньне саклау көне |
| Җәйге чорда балалар бакчасы каникуляр режимда эшли. | | | | |

**Сөйләм үстерү үсеш өлкәсе.**
**"Матур әдәбият уку"**.
Максат: әйләнә-тирә белән таныштыру; әдәби телне үстерү; сүз сәнгатенә тарту.

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| **Сентябрь** | |
| Бакчада алмалар өлгерде | 1) балаларның күз, табигать тәге күзге үзгәрешләр, җиләк-җимешләр (алма, аның билгеләре) турында күзаллауларын баету нигезендә сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру, тиңдәш кисәкләр кергән җөмләләр төзергә өйрә түне дәвам итү; 2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, сенсорик күнекмәләрен, артикуляция аппаратын үстерү; 3) күмәк эшләүгә тарту, сора уларга җавап бирү теләге тәр бияләү. |
| «Ә» авазы | 1) «ә» сузык авазын дөрес итеп, кыска һәм озын итеп әйтергә күнектерү. «Ә» авазын аерым, сүзләрдә һәм җөмләләрдә әйтүне ныгыту; 2) сорауларга җавап бирергә теләк уяту; 3) сюжетны чагылдыра торган уеннарда катнашу теләге тәр бияләү. |
| Алтын көз | 1) тиңдәш кисәклрдән тор ган җөмләләр төзергә, аерым предметлардан төркем төзергә, характерлы билгеләре буенча предметны төркемнән аерырга өйрәтүне дәвам итү; предметларның саны буенча бәйләнеш урнаштырганда, «бер», «күп», «аз», «берәү дә юк» сүз ләрен куллана, сүзләрдә [с], [з], [ф], [к] тартыкларын ачык итеп әйтә белүләренә ирешү; 2) балаларның игътибарын, зиһен гә алуларын үстерү; тәрбияче соравына аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү; табигатьнең матурлыгын аңларга өйрәтү; 3) табигатькә карата уңай мөн әсәбәт тәрбияләү. |
| “У” аваз культурасын тәрбияләү | “У” авазын артикуляцияләү ; отрабатывать полный выдох; побуждать произносить звук в разной тональности, с разной громкостью; закреплять понятия высоты, цвета; развивать умение выполнять движения под ритм музыки в сопровождении художественного слова. Стр.43 Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. |
| **Октябрь** | |
| Безнең гаилә | 1)балаларның гаилә һәм гаи лә әгъзалары турындагы белемнәрен баетуны дәвам итү; исемнәрне сан, тартым белән төрләндерүгә (әни-әниләр, әни- әнием) күнектерү; 2) балаларның игътибарын, хәтерен, аңга алуларын үстерү; 3) олылар белән ирекле ара лашу күнекмәләре; гаиләгә һәм гаилә әгъзаларына карата игътибарлылык, кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| Звуковая культура речи: звук «И» | Упражнять в четком и правильном произношении звука «И» ( изолированно, в слогах, словах); закреплять представления о различии предметов по величине; развивать силу голоса, слуховое восприятие. Стр.77 (Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. |

| | |
|---|---|
| | Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| Уенчык песи баласы турында хикәяләү | 1) балаларның гаилә турындагы күзаллауларын киңәйтү; уен чыкны карауга балаларны җәлеп итү; уенчыкны сорауларга җавап бирү юлы белән тасвирларга, тәрбияче ярдәмендә уенчык турында кыска хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү; 2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, күзәтүчәнлеген, сүз лек байлыгын үстерү; 3) тәрбияче һәм иптәшләре белән аралашу теләге уяту; йорт хайваннарына карата мәр хәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү. |
| Алсуның яңа өе. | балаларны йорт җиһаз лары белән таныштыру, билгеләнешләре буенча гомумиләштерергә өйрәтү; бирелгән сорауны аңлау һәм җавап бирүләренә ирешү; 2) җиһаз предметларының атамасын һәм билгеләнешен, аларның нинди материалдан эшләнгәнен ачыклауларына ирешү; артында, янында, өстендә кебек сүзләр хисабына сүзлек байлыгын үстерү; 3) йорт җиһазларына карата сакчыл караш тәрбияләү |

**Ноябрь**

| | |
|---|---|
| Игра-инсценировка «У матрешки нвоселье» | Формировать диалогическую речь, умение анализировать развивать восприятие цвета, формы. Стр.98 (Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| Кабатлау | Алган белмнәрен гомумиләштерү, сорауларга тулы җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү. Диалогик һәм бәйләнешле сөйләм телен үстерү |
| Төлке бездә кунакта | 1) сөйләмдә бәйлек сүзләрне (эчендә, артында, астында, өстә, өстендә) кулланырга, «кайда?, «кая?» сорауларына җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итү; 2) игътибарны, тәрбиячөнең күрсәтмәләре буенча эшләү күнекмәләрен үстерү; 3) җәнлекләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| Звуковая культура речи | Упражнять в отчетливом и правильном звкопроизношении; побуждать вступать в диалог в игровой ситуации; повторить понятия «кортокий», «длинный»; развивать музыкальный слух. Стр. 110 (Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |

**Декабрь**

| | |
|---|---|
| Звуковая культура речи: Звуки «Б», «Д». | Упражнять в четком произношении согласных звуков «б», «д» в словах; развивать умение заучивать стихотворения, вырабатывать выразительность речи. Стр. 122 (Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. |

| | |
|---|---|
| | Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| Стихотворение А. Босева «Трое» | Познакомить со стихотворением; оживить в памяти детей их собственные впечатления от катания на санках; формировать диалогоическую речь; помочь запомнить стихотворение. Стр.129 (Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| Звуковая культура речи | Упражнять детей в различении слов, похожих по звучанию; учить отчетливо проговаривать слова, отгадывать загадки. Стр. 135 (Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| Звуковая культура речи | Упражнять в правильном произношении звуков (в звукосочетаниях, словах, фразах); учить вести диалогв сюжетно- ролевой игре, петь песенку, четко проговаривая звуки и слова, воспитывать аккуратность, интерес к творческой и игровой деятельности. Стр. 142 (Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| | |

**Гыйнварь**

| | |
|---|---|
| Алсуны урамга киендерәбез. (Кышкы киемнәрне карау) | 1) кышкы киемнең бил геләнешен, төсен, аерым детальләрен, материалын атап, аны сурәтләргә; исемне сыйфат белән бәйләп, сорауларга тулы җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү; 2) тукыма, мех, йомшак, җылы, шома, ак, яшел, зәңгәр сүзләре хисабына сүзлекләрен активлаштыру, конкрет-образлы фикерләүләрен, игътибарларын, күрү хәтерләрен үстерү; 3) киемнәргә карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| Кар ява.<br><br>Карның үзенчәлекләре. | 1) балаларның кыш турында күзаллауларын киңәйтү; кар, аның билгеләре белән таныштыруны дәвам итү; сөйләмдә сыйфатларны дөрес куллана белүләренә ирешү; 2) балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, рәсем ясауга кызыксынуларын, пространствода ориентла шуларын, сөйләм сулышын үстерү; 3) башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| Звуковая культура речи: Звук «К» | Учить отчетливо произносить слова и звукоподражания со звуком «к»; закреплять произношение звука «к» в словах и фразовой речи; упражнять в произношении звукоподражаний с разной скоростью и |

| | |
|---|---|
| | громкостью; развивать воображение. Стр. 168. (Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| **Февраль** | |
| Звуковая культура речи: Звук «П». | Тренировать отчетливо и правильно произносить изолированно звук «п» и звукоподражательные слова с этим звуком. Стр. 175 (Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| Звуковая культура речи: Звук «Ф» | Учить отчетливо и правильно произносить изолированный звук «ф» и звукоподражательные слова с этим звуком; стр. 180 (Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| Звуковая культура речи: Звук «С». | Отрабатывать четкое произношение звука «с»; упражнять в умении вести диалог; закреплять представление о знакомых предметах. Стр. 186 (Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| Очучылар | 1) балаларны самолетның өлешләрен, зурлыгын, фор масын билгеләргә һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сый фатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны, [у] сузык авазын әйтүгә күнек терүне дәвам итү; очучы, очып китү, очып төшү, аска, өскә, уңга, сулга, самолет сүзләре хисабына сүзлекне активлаш тыру; 2) балаларның нинди? кайда? кая? нәрсә? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирүләренә ирешү, игътибар ларын үстерү; 3) очучы һөнәренә хөрмәт, патриотик хисләр тәрбияләү. |
| **Март** | |
| Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа! | 1) балаларның әниләр бәйрәме турындагы белемнәрен киңәйтү, [ә] авазын ачык итеп әйтүләрен камилләштерү; әңгәмәдә кат нашуга тарту; 2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, диалогик сөйләм формасын үстерү; 3) балаларда әниләргә мәхәббәт һәм аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| Звуковая культура речи: Звук «З» | Упражнять в произношении звука «з»; учить видеть и выделять красивые предметы, явления. Стр. 204 (Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |

| | |
|---|---|
| «Теремкәй» рус халык әкиятен сөйләү | 1) балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга, сюжетның эзлеклелеген күзәтә белергә өйрәтү; 2) Тычкан-Чыелдык, бака-Бакылдык, куян-Куркаккай, төлке-Хәйләбай, бүре- Сорыколак, аю-Камытаяк сүзтезмәләре хисабына балаларның сүзлеген баету, активлаштыру; игътибарны, ишетү, күрү хәтерен үстерү; 3) халык иҗатына кызыксыну тәрбияләү. |
| Звуковая культура речи: Звук «Ч`» | Упражнять в правильном произношении звука «Ч`» в словах; учить отчетливо проговаривать слова с этим звуком; развивать чувство ритма, песенные навыки. |

**Апрель**

| | |
|---|---|
| Звуковая культура речи | Отрабатывать четкое произношение слов; упражнять в умении вести диалог. Стр. 222 (Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| Заучивание стихотворение С.И. Белоусова «Весенняя гостья» | Помочь детям вспомнить стихи, которые они разучивали течении года, запомнить новое стихотворение; развивать мышление, творческие способности. Стр. 228 (Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| Бозау, колын, бәрән турында сөйлибез | 1) язгы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре турында күзаллауларын киңәйтү; тәрбияче белән бергә уенчык турында кечкенә хикәя (2-3 җөмлә) төзергә, капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне (зур – кечкенә, калын – нечкә) таба һәм куллана белергә өйрәтүне дәвам итү; балаларның аваз ияртемнәрен әйтә белүләрен ныгыту; 2) балаларның аңга алуларын, монологик сөйләмен үстерү; 3) балаларда хайваннар тормышы белән кызыксыну тәрбияләү. |
| Звуковая культура речи: звуки «С», «С`», «З», «З`», «Ц». | Упражнять в правильном произношении звуков «С», «С`», «З», «З`», «Ц» в словах. Стр. 239<br>(Комплексн6ые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| Б. Рәхмәтнең “Яз” шигырен ятлау | 1) шигырнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; сүзлекне баету һәм активлыштыру; гаилә сүзен сөйләмдә кул ланырга өйрәтү; 2) шигъри әсәрне яттан сөйләргә теләк уяту; аңга алуларын, хәтерне, игъти барны үстерү; 3) гаиләгә карата хөрмәт, туганлык хисләре тәрбияләү. |

**Май**

| | |
|---|---|
| Звуковая культура речи: | Упражнять в правильном произношении звука «ш» в словах; учить огораживать большое пространство; закреплять умение объяснять |

| | |
|---|---|
| звуки «Ш». | свои действия.<br><br>(Комплекснбые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| Автобуста сәяхәт | 1) балаларның аваз ияртемнәрен әйтә белүләренә ирешү, йорт хайваннары төшенчәсен ныгыту, йорт хайваннары, кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү; 2) кошларның, хайваннарның хәрәкәтен белдерә торган фигыльләр, иркәләп, яратып әйтелә торган сүзләр хисабына сүзлекләрен активлаштыру; балаларның игътибарын, хәтерен, аңга алуларын үстерү; 3) тере һәм тере булмаган табигать белән кызыксыну тәрбияләү. |
| Заучивание стихотворения В.Берестова «Котенок» | Помочь запомнить стихотворение; выразительно читать его. Стр. 258.<br><br>(Комплекснбые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| Мин җәйне яратам | 1) табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, билгеле бер ситуациягә туры килгән фигыльләрне сөйләмдә кулллануларын активлаштыру, «бер», «күп» төшенчәләрен ныгыту; 2) балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, уңай хис-кичерешләрен, аңга алуларын үстерү; 3) табигатькә сакчыл караш тәрбияләү |

**Танып белү (иң гади математик күзаллауныүстерү)**

| Атна | Тема | Максат | Методик чыганак |
|---|---|---|---|
| **Сентябрь** | “Аю баласына булышыйк” | Геометрик фигураларны таный һәм дөрес әйтә белүләрен ногыту | конспект |
| | “Аю баласында кунакта” | Зур, кечерәк, тагын да кечкенә сүзләрне куллану. | конспект |
| | “Шар” һәм “Куб” | Балаларны шар һәм кубны төсләренә һәм зурлыклары буенча аера белү. “аз”, “күп”, “бер” сүзләрен куллану. | И.А.Помораева 11 бит |
| | “Зур”, “кечкенә” | Балаларны предметларны чагыштырырга өйрәтү. | И.А.Помораева 12 бит |
| **Октябрь** | “Аз, күп, бер” | Балаларны предметларны формалары (түгәрәк, квадрат) буенча төркемләргә өйрәтү. | И.А.Помораева 12бит |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | “Аз, күп, бер” (ныгыту) | Балаларны өчпочмак белән таныштыру, фигураларны төсләре һәм исемнәре буенча төркемләргә өйрәтү. | И.А.Помораева 13 бит |
| | “Күпме” | Геометрик фигураларны: өчпочмак, квадрат, түгәрәк аерырга һәм әйтергә өйрәнү. | И.А.Помораева 14 бит |
| | “Күпме” | Бер төркем предметларны икенче төркем белән чагыштырырга өйрәнү, тигезлек һәм тигезсезлек билгеләре белән танышу, предметларны бер-берсенә куеп санамыйча чагыштыру, уң һәм сул кулны аерырга өйрәнү. | И.А.Помораева 15бит |
| | “Күпме, тигез” | Күпме, тигез, аз, күп, бер сүзләрен кулланып ике төркемдәге предметларны чагыштыру. | И.А.Помораева 16 бит |
| Ноябрь | “Тирә-юньдә ориентлашу” | Аста, өстә сүзләрен кулланып тирә-юньдә предметларны табарга өйрәтү, ике төркем предметларны чагыштыру. | И.А.Помораева 17 бит |
| | “Түгәрәк һәм квадрат” | Балаларны квадрат белән таныштыру, түгәрәк һәм квадратны аерырга өйрәтү | И.А.Помораева 18 бит |
| | “Түгәрәк һәм квадрат” (ныгыту) | Балаларны түгәрәк һәм квадратны аерырга өйрәтү, предметларны формалары буенча төркемләргә өйрәнү. | И.А.Помораева 19 бит |
| | “Тәгәри китте йомгагым” | Предметларны озынлыклары буенча чагыштыруны дәвам итү, алда, артта, аста, өстә сүзләрен кулланырга өйрәнү. | конспект |
| **Декабрь** | “Предметларны озынлык буенча чагыштыру” (ныгыту) | Предметларны озынлыклары буенча чагыштыруны дәвам итү, алда, артта, аста, өстә сүзләрен кулланырга өйрәнү. | И.А.Помораева 19 бит |
| | “Предметларны озынлык буенча чагыштыру” (ныгыту) | Предметларны озынлыклары буенча чагыштыруны дәвам итү, геометрик фигураларны: аера белү. | И.А.Помораева 20 бит |
| | Үз гәүдәләрендә орентлашу | Предметларны киңлекләре буенча чагыштырырга өйрәтү, уң һәм сул кулларын күрсәтә белү. | И.А.Помораева 21 бит |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | “Предметларны киңлек буенча чагыштыру” (ныгыту) | Киң, тар сүзләрен кулланып ике төркем предметларны киңлекләре буенча чагыштырырга өйрәнүне дәвам итү. | И.А.Помораева 22 бит |
| **Январь** | “Предметларны киңлек буенча чагыштыру” (ныгыту) | Предметларны киңлекләре буенча чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү. | И.А.Помораева 23 бит |
| | “Ике төркем предметларны чагыштыру” | Ике төркем предметны микъдарлары (тигез һәм тигез түгел) буенча чагыштырырга өйрәнү. | И.А.Помораева 24 бит |
| | “Предметларны киңлек буенча чагыштыру” (ныгыту) | Ике төркем предметларны киңлекләре буенча чагыштырырга өйрәнүне дәвам итү, | И.А.Помораева 26 бит |
| **Февраль** | “Ике төркем предметларны чагыштыру” (ныгыту) | Ике төркем предметны зурлыклары буенча чагыштырырга өйрәнү, тирә-юньдә ориентлаша белү. | И.А.Помораева 27 бит |
| | “Ике төркем предметларны чагыштыру” (ныгыту) | Ике төркем предметлар арасында тигезлек булдырырга өйрәнү, тирә-юньдә ориентлаша белү. | И.А.Помораева 28 бит |
| | “Предметларны биеклек буенча чагыштыру” | Биек – тәбәнәк сүзләрен кулланып ике предметны биеклек буенча чагыштыру. | И.А.Помораева 29 бит |
| | “Предметларны биеклек буенча чагыштыру” (ныгыту) | Биек – тәбәнәк сүзләрен кулланып ике предметны биеклек буенча чагыштыруны дәвам итү, геометрик фигураларны әйтә белү. | И.А.Помораева 30 бит |
| **Март** | “Предметларны биеклек буенча чагыштыру” (ныгыту) | Предметларны бер билге буенча гына төркемләргә өйрәнү. | И.А.Помораева 31 бит |
| | Предметларны зурлык буенча чагыштыру. | Зур - кечкенә сүзләрен кулланып ике предметны зурлык буенча чагыштыру. | И.А.Помораева 33 бит |
| | Предметларны зурлык буенча чагыштыру. (ныгыту) | Зур - кечкенә сүзләрен кулланып ике предметны зурлык буенча чагыштыруны дәвам итү. | И.А.Помораева 34 бит |
| | “Көн-төн” | Көн һәм төнне аерырга өйрәнү, предметларны озынлыклары буенча чагыштыруны дәвам итү, геометрик фигуралардан рәсемнәр төзү. | И.А.Помораева 35 бит |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Апрель | Предметларны зурлык буенча чагыштыру. (ныгыту) | Предметларны зурлык буенча чагыштыруны дәвам итү, ике төркем предметны чагыштыру. | И.А.Помораева 36 бит |
| | Предметларны зурлык буенча чагыштыру. (ныгыту) | Зуррак, кечкенәрәк, тигез сүзләрен кулланып предметларны зурлык буенча чагыштыруны дәвам итү. | И.А.Помораева 37 бит |
| | "Алда – артта, унда – сулда" | Зуррак, кечкенәрәк, тигез сүзләрен кулланып предметларны зурлык буенча чагыштыруны дәвам итү, тирә юнь.дә орентлашуны өйрәнү | И.А.Помораева 38 бит |
| | "Аерым предметлардан бер төркем предметлар" | Үткән материалларны кабатлау, предметларны төркемләргә өйрәнү, предметларны чагыштыру, тирә – юньдә һәм вакытта ориентлаша белү. | И.А.Помораева 39 бит |
| Май | "Күп, бер" | Үткән материалларны кабатлау, предметларны төркемләргә өйрәнү, предметларны чагыштыру, | И.А.Помораева 40 бит |
| | "Тирә – юньдә орентлашуны" | Үткән материалларны кабатлау, предметларны төркемләргә өйрәнү, предметларны чагыштыру, тирә – юньдә һәм вакытта ориентлаша белү. | И.А.Помораева 41 бит |
| | "Геометрик фигураларны кабатлау" | Үткән материалларны кабатлау, предметларны төркемләргә бүләргә өйрәнү, предметларны чагыштыру. | И.А.Помораева 42 бит |
| | "Тәүлек кисәкләре" | Үткән материалларны кабатлау, тәүлек кисәкләрен бүләргә предметларны төркемләргә өйрәнү, предметларны чагыштыру | И.А.Помораева 43 бит |
| | Үткәннәрне кабатлау. | Үткән материалларны кабатлау, тәүлек кисәкләрен бүләргә предметларны төркемләргә өйрәнү, предметларны чагыштыру | И.А.Помораева 43 бит |

**Танып-белү (әйләнә-тирә белән танышу)**

| ***ай*** | ***тема*** | ***бит*** | ***максат*** |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| сентябрь | Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы! | 16 | балаларга табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турында мәгълүмат бирү, яшелчәләр (кишер, помидор) турындагы белемнәрен ны гыту; балаларның яшелчәләрне (кишер, помидор) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белүләренә ирешү; игътибарын, аңга алуларын, диалогик сөйләмен, сенсорик күнекмәләрен үстерү; балаларда сорауларга җавап бирү теләге уяту; табигатькә уңай караш тәрбияләү |
| | “Транспорт” | 19 | Транспорт төрләре белән таныштыру |
| | Бакчадан яшелчәләр (экологик белем бирү) | 8 | Тышкы билгеләре буенча һәм тәме буенча яшелчәләрнең исемнәрен ныгыту ( кыяр, помидор, кишер, шалкан). Яшелчә культурасы белән таныштыруны дәвам итү. “Шалкан” әкиятен сәхнәләштерүгә кызыксыну уяту (Соломенникова Занятия по формированию элементарных экологических представлений во второй мл.гр. д/с. ). |
| | Йомшак кай әзерләгән сюрприз | 18 | агачтан ясалган уенчыкларны карау барышында агач материалы, аның үзлекләре (каты, нык) белән таныштыру; тәрбияче сорауларына җавап бирергәөйрәтүпредметларның төсен, формасын, зурлыгын билгели белергә өйрәтү, анализаторлар эшчәнлеген,сүзлекбайлыгын,хәтерләрен, игътибарларын үстерү;уенчыкларга карата сакчыл караш, уеннан соң уенчыкларны урынына кую гадәте тәрбияләү |
| Октябрь | | | мониторинг |
| | Ак каенда кунакта | 34 | Балаларны каен агачы белән таныштыру |
| | Куян үстергән кишер һәм помидор | 28 | балаларга табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турында мәгълүмат бирү, яшелчәләр (кишер, помидор) турындагы белемнәрен ны гыту; балаларның яшелчәләрне (кишер, помидор) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белүләренә ирешү; игътибарын, аңга алуларын, диалогик сөйләмен, сенсорик күнекмәләрен үстерү;балаларда сорауларга җавап бирү теләге уяту; табигатькә уңай караш тәрбияләү |
| | Сары кызыл яфраклар | 31 | .балаларны көз, кыш ел фасылларының характерлы билгеләре белән таныштыру; бер ел вакыты икенчесен алмаштыруы турында мәгълүмат бирү; көзге яфраклар турындагы белемнәрен (яфракларның төсләре үзгәрә, алар коелалар) киңәйтү. Авазлар әйтелешен ныгыту; балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, бәйләнешле сөйләмен үстерү; көзге табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәтү; балаларда чиста, пөхтә эшләү теләге тәрбияләү |
| | Әбием мине сагынган | 37 | Гаилә турында күзаллау үстерү, гаилә әгъзаларын атый белергә өйрәтү, якыннарга карата ярату кайгырту хисләре тәрбияләү.Әби-бабайга хөрмәт тәрбияләү |
| | “Тылсымлы капчык” | | Предметларның кеше кулы белән һәм табигать тарафыннан ясалган булуларын аңлату. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Кунак каршылыйбыз | 34 | савыт-сабаның аерым предметлары, аларның кулланылышы турында беле мнәренә төгәллек кертү; тәрбияче белән бергә кыска хикәя төзергә өйрәнүне дәвам итү; әңгәмәгә тарту; балаларның игътибарын, аңга алуларын үстерү; тәрбияче биргән сорауны ишетү, аңлау һәм аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү; үз исемен дөрес итеп әйтә белергә өйрәтү; балаларда сөйләм этикетына нигез салу (исәнләшү, танышу, саубуллашу); өлкәннәргә булышу теләге уяту; савыт-сабага сакчыл караш тәрбияләү |
| | Куян сәяхәткә чакыра | 44 | Табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр арасындагы гади бәйләнешләрне билгеләргә өйрәтү; җәнлнкләрнең үз-үзләрен тотышы,балалары турында белемнәрен үстерү. Игътибарлылык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | Әбидә кунакта (экологик белем бирү | 12 | Балаларны йорт хайваннары һәм аларның балалары белән таныштыруны дәвам итү. Дөрес итеп хайван иесмнәрен атарага өйрәтүне булдыру. Аларга карата сакчыл караш тәрбияләү. (Соломенникова Занятия по формированию элементарных экологических представлений во второй мл.гр. д/с. ). |
| | Теремкәй | | Балаларны агачның сыйфаты , структурасы белән таныштыру. Тимер белән чагыштырп карау. |
| Декабрь | Минем йортым, минем шәһәрем | 79 | балаларны туган шәһәр, аның исеме (Яр Чаллы), шәһәрдә ясала торган «КамАЗ» машинасы белән таныштыру, юл йөрү кагыйдәләре турында элементар белемнәр бирү; аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен үстерү; сүз ләрне, кыска фразаларны ачык әйтә белүләренә ирешү; «КамАЗ» машиналары белән кызыксынуларын үстерү туган шәһәр, «КамАЗ» эшчеләре, аларның хезмәте белән горурлану хисе тәрбияләү. |
| | Элекр лампасы белән таныштыру | Конспект,рәсем буенча | Электр турында балаларга гади төшенчә бирү; балаларның игътибарын, хәтерен ток белән бәйләнешле булган куркынычсызлык кагыйдәләрен балаларга җиткерү.Сакчыллык тәрбияләү. |
| | Гирлянда | Рәсем буенча | Балаларга гирлянда турында башлангыч белемнәр бирү; электр тогы турындагы күзаллауларын ныгыту, төсләрен таный һәм аера белергә күнектерү.Сүз байлыгын киңәйтү.Күмәк эшчәнлектә катнашу теләге тәрбияләү. |
| | Куян белән төлкене яшел чыршы бәйрәменә чакырабыз | 85 | Балалр белән бергә чыршыны карау.Яңа ел бәйрәме турында күзаллау киңәйтү һәм баету.Матурлыкны күрә һәм аңа соклана белү хисләре, чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | Кошларны кышын җим белән сыйла! | 15 | Кышның үзенчәлекле яклары белән таныштыруны дәвам итү. Җимлек белән таныштыру. Кышын кошларны ашату теләге уяту. Кышлаучы кошлар турында белемнәрен камилләштерү. (Соломенникова Занятия по формированию элементарных экологических представлений во второй мл.гр. д/с. ). |
| Гыйнвар | Ап-ак кар ява | 89 | Баларны кар һәм аның үзлекләре( ак төстә,эри, йомшак, салкын,җиңел)белән таныштыру;тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү.Кышкы табигатькә соклану хисе, бергәләп уйнау теләге тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Алсу урамга җыена | 88 | Балаларның кышкфы киемнәр турында белемнәренә төгәллек кетү, урамга чыкканда киенү эзлеклеген һәм киемнәрен истә калдырырга өйрәтү.башкаларга ярдәм итү теләге булдыру, киемнәргә сакчыл караш тәрбияләү. |
| **Феврвль** | Гыйнварьдә ишегалдында күп кар | 17 | Кышкы табигать үзгәрешләре турында белемнәрен тикшерү. Әйләнә-тирә табигатькә каратаэстетик караш формалаштыру. Сүзлек байлыгын активлаштыру һәм баету.<br>(Соломенникова Занятия по формированию элементарных экологических представлений во второй мл.гр. д/с. ). |
| | “Миндә песи баласы яши” | 18 | Йорт хайваннары белән таныштыруны дәвам итү. Хайваннар белән аралашу үрнәкләре белән таныштыру. Күзәтүчәнлекләрен үстерү. Алган тойгылары белән аралауны булдыру.<br>(Соломенникова Занятия по формированию элементарных экологических представлений во второй мл.гр. д/с. ). |
| | Алсу бәйрәмгә җыена | Рәсем буенча | Өс киемнәре аларның төсе һәм материалы белән таныштыруны дәвам итү; сүзлекне активлаштыру.Балалрның фикерләвен, сорuларгы бавапп бирү, осталыгын үстерү.Курчаклар белән уйнарга теләк уяту, сакчыл караш тәрбияләү. |
| | Ватанны саклаучылар көне | 49 | балаларны Ватанны саклаучылар көне белән таныштыру; балаларның игътибарын, аңга алуларын; диалогик, сөйләмнәрен үстерү; балаларда Туган илгә мәхәббәт, малайларда көчле, кыю булырга омтылыш тәрбияләү |
| | Транс порт төрләре | конспек т | Балаларны транспорт төрләре белән таныштыруны дәвам итү. Светофорның өч төсен ныгыту. Юлда сак булу күнекмәләре бирү. |
| Март | Минем әнием | 52 | .Балаларны әниләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү,эш- хәрәкәтне белдерә торган сүзләр хисабынасүз байлыгын киңәйтү.Кабул итү сәләтен үстерү.Зниләр хезмәтенә карата кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү. |
| | Едем в гости к бабушке | 195 | Познакомить с признаками весны: солнышко светит ярче, капель, на дорожках тает снег; развивать наблюдательность. (Комплекснбые занятия по программе «от рождения до школы под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Младшая группа (от3 до 4 лет) /авт.-сост. Т.В. Ковригина, М.В. Косьяненко, О.В. Павлова.- Волгоград: Учитель, 2014) |
| | Бүлмә гөлләрен карау. | 20 | Бүлмә гөлләре турында күзаллауларын үстерү. (Кливия). Су сипкечтән гөлләргә дөрес итеп су сибү күнекмәләре белән таныштыру. Юеш чүпрәк белән яфракларындагы тузаннарны сөртергә өйрәтү. Аларга кара та кызыксыну уяту. |
| | Без балалар бакчасында нәрсәләр эшлибез | 42 | Балалр бакчасы хезмәткәрләренең хезмәте белән таныштыру. |
| Апрель | Урамда яз | 56 | Балаларга язгы күренешләр турында башлангыч белемнәр(кар эри, тамчы тама, кояш җылыта)бирү.Сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру. Балаларның күзәтүчәнлеген үстерү.Табигатьтәге язгы күренешләр белән кызыксындыру. |

**Сынлы сәнгать эшчәнлеге (әвәләү).**

**Сентябрь**

| Тема | 1-2 нче атна<br>**Балчык, пластилин белән танышу** | 3-4 нче атна<br>**Таяклар (Конфетлар)** |
|---|---|---|
| Максат: | Балчык үзлекләре (йомшак; тәгәрәтеп булганы ) турында күзаллау бирү. Балчыкны<br>тактага куеп пөхтә эшләргә, пластилинны балчыктан аерырга өйрәтү. | Балчыктан кечкенә кмсәкләр чеметеп алырга, учлар арасында түгәрәк хәрәкәтләр белән әвәләргә өйрәтү.Пөхтә эшләргә, әзер эшне тактага куярга өйрәтү.Әвәләү теләге уяту. |
| Балалар эшчәнлеге<br>нең төре | Балаларга балчыкны кысып , кечкенә кисәкләргә өзеп алып, учлар белән ямшәйтеп булуын күрсәтү. Җиңнәрне сызганырга һәм балчык алып эшләп карарга тәкъдим итү. | Балаларга матур таяклар әвәләргә тәкдим итү. Санау таякчыклары, конфетлар карау. Балчыкны чеметеп алуны туры хәрәкәтләр белән әвәләүне күрсәтү. Әзер эшләрне киштәгә кую. |

**Октябрь**

| Тема | 1 -2 нче атна<br>**Төрле төсле акбурлар** | 3-4 нче атна<br>**Клиндерләр** |
|---|---|---|
| Максат: | Ике уч төбе арасында туры хәрәкәтләр белән әвәләргә өйрәтүне дәвам итү.Әвәләгән эшне, артык балчыкны тактага куярга өйрәтү. Әвәләү теләге уяту, шатлану. | Балаларны балчык белән таныштыруны дәвам итү, балчык таякчыкны йөзек кебек (башларын бер берсенә кысып таташтырырга) өйрәтү. Балчыкны туры хәрәкәтләр белән әвәләүне ныгыту. |
| Балалар эшчәнлеге<br>нең төре | Балаларга төсле акбурлар күрсәтү. Һавада кул хәрәкәтләре белән әвәләп күрсәтү. Әвәләргә тәкъдим итү. | Клиндер карау.Нинди формада булуын сорау. Клиндер әвәләргә тәкъдим итү.Калын калбасаны йөзек кебек бөкләргә, башларын бер берсенә нык итеп ябыштырырга өйрәтү. Эшне башларга әйтү. Әвәләү алымына игътибар итү. |

**Ноябрь**

| Тема | 1-2нче атна | 3-4 нче атна |
|---|---|---|

| | **Йомры икмәк** | **Песиемә бүләк** |
|---|---|---|
| Максат: | Әкият персонажлары образын барлыкка ктерү теләге тудыру. Балчыкны уч төбендә түгәрәк хәрәкәтләр белән әвәләүне ныгыту. Кайбер өлешләрен таякчык белән ясарга өйрәтү. | Элек алган күнекмәләрне кулланырга өйрәтү. Хайваннарга карата сакчыл караш тәрбияләү. Күзаллауны үстерү. |
| Балалар эшчәнлегенең төре | Балалар белән “Йомры икмәк” әкиятен искә төшерү. Йомры икмәкне әвәләргә тәкъдим итү. Формасын һәм ничек әвәләү ысулын ачыклау. Авыз, күзләр ясау өчен таякчыклар бирү. | Балалар белән песиләр, этләр турында сөйләшү: алар нәрсә ашыйлар (колбаса, сөяк), нәрсә белән уйнарга (туп, шар, сөяк һ.б.) яраталар. Яраткан песиләргә бүләк әвәләргә тәкъдим итү. Эш барышында балаларга ярдәм итү. |

**Декабрь**

| Тема | 1-2нче атна<br>**Уйлап әвәләү.** | 3-4 нче атна<br>**Клиндерләр** |
|---|---|---|
| Максат: | Уйлап чыгарган предметларны атарга өйрәтү. Үзлектән эшли белүне үстерү. | Учларның туры хәрәкәте белән әвәләү ысулын ныгыту. Колбасаны төрлечә бөкләргә өйрәтү. Охшаш һәм аермалыкларны табарга, эшләрнең төрле булуын күрергә өйрәтү. |
| Балалар эшчәнле-генең төре | Балалар белән нәрсәләр әвәләгәнне искә төшерү. Нәрсә әвәләргә теләгәнне уйларга тәкъдим итү. Берничә уенчык кую, аларның формасын ачыклау. Мөстәкыйль әвәләгән балаларны мактау. | Алдан әвәләгән һәм чын клиндерләрне карау. Әвәләү ысулын искә ачыклау. Курчаклар белән уйнар өчен клиндерләр әвәләргә тәкъдим итү. |

**Январь**

| Тема | 1-2нче атна<br>**Прәннекләр** | 3-4нче атна<br>**Уйлап әвәләү.** |
|---|---|---|
| Максат | Балаларны шариклар әвәли белүләрен ныгыту. Учлар белән | Өйрәнгән әвәләү ысулларын ныгыту. Уйлап чыгарган предметларны атарга |

| | | |
|---|---|---|
| : | басып шарны ямшәйтергә өйрәтү. Әвәләү теләген үстерү. | өйрәтү. Үзлектән эшли белүне үстерү. Иҗадилыкны һәм мөстәкыйльлелекне үстерү. |
| Балалар эшчәнлеге нең төре | Катя исемле курчакны чакыру, аның туган көне. Аңа тәмле прәннекләр әвәләргә тәкъдим итү. Түгәрәк прәннекне карау: формасын ачыклау. Аның өстән һәм астан кысып ясалганына игътибар итү. Берничә прәннек әвәләргә мөмкин. Төсле кәгазь кисәкләре белән прәннекне бизәү. | Нәрсә һәм ничек әвәләгәнне искә төшерү. Бүген нәрсә телиләр шуны әвәләргә мөмкин. Балалардан нәрсә әвәләргә теләгәнне сорашу. Эшләрне карау һәм мактау. |

**Февраль**

| Тема | 1-2 нче атна<br><br>**Печенье** | 3-4 нче атна<br><br>**Зур һәм кечкенә җәймәләр** |
|---|---|---|
| Максат: | Балчыкны түгәрәк хәрәкәтләр белән тәгәрәтә белүләрен ныгыту; шарны учлар белән ямшәйтү. Әвәләү теләген үстерү. Пластилин белән пөхтә эшли белүне | Зур балчыктан кечкенә кисәкләр өзеп алырга өйрәтүне дәвам итү. Түгәрәк хәрәкәтләр белән тәгәрәтү. Учлар белән шарны ямшәйтә белүне ныгыту. |
| Балалар эшчәнлеге нең төре | Курчаклар белән уйнау.(Туган көн, кибеткунаклар, ) өчен печенье әвәләргә тәкъдим итү.Печеньены карау: формасын ачыклау (түгәрәк, җәйпәк). | Балаларга әвәләү ысулын һавада кул хәрәкәтләре белән күрсәтергә тәкъдим итү. “Ә аннан соң нишләргә?” диеп балаларны активлаштыру. |

**Март**

| Тема | 1-2 нче атна<br><br>**Шалтыравык** | 3-4нче атна<br><br>**Башня (түгәрәкләрдән пирамидка)** |
|---|---|---|
| Максат: | 2 өлештән торган (шар һәм таяк) әйбер әвәләргә өйрәтү. Өлешләрне бер берсенә кысып ябыштыру. Учларның түгәрәк һәм туры хәрәкәте белән әвәләү . | Балчыкны түгәрәк хәрәкәтләр белән тәгәрәтеп әвәләү ысулына өйрәтүне дәвам итү. Берничә өлештән торган әйбер ясау. Пөхтә әвәләүне ныгыту. |

| | | |
|---|---|---|
| Балалар эшчәнлеге нең төре | Балалар белән 2-3 шалтыравык карау: формасын һәм төзелешен ачыклау. Әвәләү ысулын балалардан сорау. Эш барышында әвәләү ысулын дөрес куллануларын күзәтү. | Балалар белән башняны карау: нинди өлешләрдән төзелүен ачыклау. Һавада кул хәрәкәте белән түгәрәк хәрәкәт белән әвәләүне күрсәтергә тәкъдим итү. Төрле зурлыктагы түгәрәкләр әвәләргә өйрәтү. Әвәләгән әйберләрне карау, шатлану. |

**Апрель**

| Тема | 1-2 нче атна<br>**Уйлап әвәләү** | 3-4нче атна<br>**Әфлисун һәм мандариннар** |
|---|---|---|
| Максат: | Үз эшеңнең эчтәлеген үзлектән уйлый белүне үстерүне дәвам итү. Төрле әвәләү ысулы белән куллану. | Түгәрәк формадагы предметлар әвәли белүне ныгыту. Төрле зурлыктагы предметлар әвәләргә өйрәтү. |
| Балалар эшчәнле-генең төре | Балаларга матур уенчыкларны, әйберләрне атарга тәкъдим итү. Кем нәрсә тели шуны әвәли ала. Мөстәкыйльлек һәм иҗадилыкны мактау. | Төрле зурлыктагы әфлисун һәм мандариннар карау: формасын һәм зурлыгын ачыклау. Зур һәм кечкенә әйберләр әвәләү өчен кирәкле балчыкның күләмен ачыклау. Эшләрне бергәләп карау, шатлану. |

**Май**

| Тема | 1-2нче атна<br>**Аюга туган көн күчтәнәчләре** | 3-4 нче атна<br>**Яраткан уенчыгыңны әвәлә.** |
|---|---|---|
| Максат: | Әвәләү алымнарын, материаллар белән пөхтә итеп эшли белүне ныгыту. Иҗатны һәм күз алына китерү сәләтен үстерү. | Үз эшеңнең эчтәлеген үзлектән уйлый белүне үстерүне дәвам итү. Бер һәм берничә өлештән торган әйбер әвәләүне ныгыту. Мөстәкыйль әвәләүдән шатлану хисе уяту. |
| Балалар эшчәнлеге нең төре | Бүген аюның туган көне, аңа бәйрәм оештырырга тәкдим итү. Төрле тәмле әйберләр әвәләргә тәкдим итү. Әвәләү ысулын искә төшерү. Эшләрне подноска куеп уен почмагына кую. | Балаларга яраткан уенчыкларны атарга тәкъдим итү; формасын, зурлыгын ачыклау. Балчык (пластилин) белән пөхтә эш итүгә игътибар итү. |

**Танып белү (конструкцияләү).**

| Ай | № | Тема | Максат |
|---|---|---|---|
| С Е Н Т Я Б Р | 1. | Биек йорт һәм баскыч. | Биеклек һәм төс аңлатмаларын ныгыту; ничек төзүләре турында сөйләргә, үрнәк буенча төзергә өйрәтү, төзелеә детальләрен таный һәм әөтә белү осталыкларын үстерү. |
| | 2. | Биек йорт һәм баскыч. | Корылма үрнәкләрен анализларга: төп өлешләрен аерырга,зурлыклары, формалары буенча таный белергә өйрәтү, төзелеш детальләре белән таныштыруны дәвам итү, төзелеш материалларына сак караш тәрбияләү (авызга капмаска һ.б.). |
| О К Т Я Б Р Ь | 1. | Биек йортлар һәм баскычлар. | Төрле төстәге детальләрдән файдаланып, корылмалар төзергә өйрәтү, аерым өлешләрнең бер-берсенә карата тирәлектә торышын(йорт стеналары, түбәсе) ачыкларга өйрәтү. |
| | 2. | Юллар. | Төрле озынлыктагы юллар төзергә, корылманы мөстәкыйль рәвештә киңлеккә,озынлыкка үзгәртергә өйрәтү; төсе,зурлыгы буенча предметларны туры китереп сайлый белү күнекмәләрен ныгытырга; өлкәннәр тормышына һәм хезмәтенә кызыксыну уяту. |
| Н О Я Б Р Ь | 1. | Калач өчен юл. | Озынлык һәм төсләр турында белемнәрен ныгыту; |
| | 2. | Курчаклар өчен җиһазлар. | Төзү алымнарын күрсәтмичә, үрнәк буенча төзергә , эшнең нәтиҗәсен анализларга өйрәтү. |
| Д Е К А Б Р Ь | 1. | Диван һәм кәнәфи. | “Кәнәфи кыска”, “диван озын” аңлатмасын бирү;<br>мөстәкыйльэшләү күнекмәләрен үстерү. |
| | 2. | Капкалар. | Корылманы биеклеккә үзгәртергә өйрәтү; детальләрне: кирпечләр, шакмаклар дип атарга күнектерү. |
| Я Н В А Р Ь | 1. | Капкалар. | Биек һәм тәбәнәк капкалар төзергә, төзелешләрне сүтеп, материалларны савытына җыеп куярга өйрәтү. |
| | 2. | Капкалар | Төзелешләрне төрлечә үзгәртергә өйрәтү, биеклеген, озынлыгын, киңлеген билгеләргә, нинди детальләр кулануларын аңлатырга өйрәтү. |
| Ф Е В | 1. | Өй. | Катлауландырылган төзелешләр башкарырга тәкъдим итү.Төзелеш материалларының төсенә,бизәлешенә игътибар бирү, тирәлектә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Р<br>А<br>Л<br>Ь | | | яраклашырга өйрәтү. |
| | 2. | Курчаклар өчен җиһазлар. | Таныш предметлар турында күзаллауларын ныгыту, төзелеш материалларының исемнәрен дөрес атарга өйрәтүне дәвам итү, төзүгә кызыксыну тәрбияләү. |
| М<br>А<br>Р<br>Т | 1. | Әниемә бүләгем. | Әниләргә карата шәфкатьлелек тәрбияләү; әниләрне үз куллары белән ясаган бүләкләр белән сөендерергә әзерләү; башлаган эшне ахыргача башкарырга өйрәтү. |
| А<br>П<br>Р<br>Е<br>Л<br>Ь | 1. | Машиналар өчен капкалар. | Төрле биеклектәге төрле-төрле капкалар ясарга өйрәтү. |
| | 2. | Өй. | Өй төзергә, өй тирәли коймалар урнаштырырга өйрәтү, төзелгән өй янында төрле- төрле йорт хайваннары, вак уенчыклар белән уеннар оештырырга күнектерү; төзелешне яхшылап сүтәргә һәм детальләрне төсе һәм төре буенча урыннарына урнаштырырга күнектерү. |
| М<br>А<br>Й | 1. | Койма. | Зур тирәлекне коймалар белән әйләндереп алырга өйрәтү(үрдәкләр өчен күлне).Башлаган эшне ахыргача башкару күнекмәләрен үстерү. |
| | 2. | Комнан төзелешләр. | Комның үзлекләре турында белемнәрен ныгыту.Төрле корылмалар,юллар( өстәл, эскәмия,эт оясы, башня һ.б.) төзергә өйрәтү. |

**Сынлы сәнгать эшчәнлеге. (кисеп-ябыштыру)**
**Сентябрь**

| Тема: | **2**нче атна<br><br>**Зур һәм кечкенә туплар** | **4**нче атна<br><br>**Юл буенча шарлар тәгәри** |
|---|---|---|
| Максат: | Балаларны зур һәм кечкенә түгәрәк формадагы әйберләр сайларга өйрәтү. Түгәрәк формадагы әйберләр турында күзаллауны, аларны зурлыгы буенча аера белүне ныгыту. Пөхтә итеп ябыштырырга өйрәтү. | Балаларны түгәрәк формадагы әйберләр белән таныштыру. Форма контуры буенча бармак белән йөртергә этәрү. Ябыштыру алымнарына ( өлешнең икенче ягына җилем сөртергә, җилемне әз-әзләп алырга, сүрәтне кәгазьгә салфетка белән кысып ябыштыру) өйрәтү. |
| Балалар эшчәнле-генең төре | Балаларга зур һәм кечкенә туплар тәгәрәтүне күрсәтү. Алар шуны сүрәтләп ябыштырырга кирәклеген әйтү. Ничек эшне башкарырга кирәклеген аңлату. Пөхтә итеп ябыштыра белүләрен күзәтү. | Балаларга “юл”ны (кәгазь тасмасын) күрсәтү, алар буйлап шарлар тәгәри. Үрнәк эшне күрсәтү. Ябыштыру тәртибен күрсәтеп аңлату. Эш ахырында озын тасмада матур шарлар тәгәрәгәненә игътибар итү. |

**Октябрь**

| Тема: | **2** нче атна<br><br>**Тәлинкәдә зур һәм кечкенә алмалар** | **4** нче атна<br><br>**Җиләк-җимешләр һәм алмалар тәлинкәдә** |
|---|---|---|
| Максат: | Балаларны түгәрәк әйберләр ябыштырырга өйрәтү. Әйберләрне зурлыгы буенча төрлелеген күзаллый белүләрен ныгыту. Дөрес ябыштыру алымнарын ныгыту. | Әйберләрнең формасы турында балаларның белемнәрен ныгыту. Әйберләрне зурлыгы буенча аера белергә өйрәтү. Җилем белән пөхтә эшләү, салфетка белән эшләү. Сүрәтне кәгазьдә урнаштыра белергә өйрәтү. |
| Балалар эшчәнле-генең төре | Балаларга зур һәм кечкенә түгәрәк алмалар күрсәтү. Зур ак түгәрәк кәгазь – бу тәлинкә икәнен аңлату. Шул тәлинкәгә алмаларны ябыштырырга тәкъдим итү. | Балалар белән җиләк-җимешләр һәм алмаларны карау. Аларның формасы һәм зурлыгын ачыклау. Ябыштыру алымнарын искә төшерү һәм эшкә керешү. Йомгклау:җиләк-җимешләр һәм алмаларны төрлечә урнаштыруга игътибар итү. |

**Ноябрь**

| Тема: | **2** нче атна<br><br>**Йортларда төрле төсле утлар** | **4** нче атна<br><br>**Полосада кисеп ябыштыру. Шарлар һәм шакмаклар** |
|---|---|---|
| Максат: | Тәгәрәк формадагы әйберләр ябыштырырга өйрәтү, форманың исемен ачыклау. Түгәрәкләрне төсләре буенча чиратлаштырырга өйрәтү. Пөхтә итеп ябыштыру. Төсләр турында (кызыл, сары, яшел, зәңгәр) белемнәрен ныгыту. | Яңа форма-квадрат белән таныштыру. Түгәрәк һәм квадратны чагыштырырга, фигураларны чиратлаштырып ябыштырырга өйрәтү. Төсләр турында белемнәрен ачыклау. |
| Балалар эшчәнле-генең төре | Утлар белән бизәлгән шәһәр, тәрәзәләр<br><br>дәге төсле утларны искә төшерү. Балалар<br><br>га утларны тасмага төсләрен чиратлашты<br><br>рып урнаштырырга тәкдим итү. Ябыш-тыру алымнарын искә төшерү һәм эшкә керешү. | Балаларга шарлар һәм шакмаклар күрсәтү, аларның аермалыгын сорау. Фигураларны контуры буенча йөртү, түгәрәкең салмак сызыгына, квадратның почмакларына игътибар итү. Түгәрәк һәм квадратны чагыштырып ябыштыру. |

**Декабрь**

| Тема: | **2** нче атна<br><br>**Пирамида** | **4** нче атна<br><br>**Нинди уенчык телисең, шуны ябыштыр** |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| Максат: | Балаларны берничә өлештән торган уенчык образы ябыштырырга өйрәтү.Зурлыгы буенча кими бару тәртибендә урнаштыру. Төсләр турында белемнәрен ныгыту. Төсләр тоемлауны үстерү. | Балаларның иҗади, уйлау сәләтләрен үстерү. Форма һәм зурлык турында белемнәрен ныгыту. Сүрәтне өлешләрдән төзү, дөрес ябыштыру алымнарына күнектерү |
| Балалар эшчәнле-генең төре | Балалар белән пирамиданы карау: өлешләрен, зурлыгын билгеләү. Балалар белән ябыштыру тәртибен ачыклау. Дөрес ябыштыру алым-нарына балаларның игътибарын юнәлтү. Барлык пирамидаларны да бергәләп карау, иң матурларын билгеләү. | Балаларны түгәрәк формадагы һәм түгәрәк өлешләрдән торган уенчыклар атый белүләрен үстерү.Уйларга һәм нинди уенчык телисең, шуны ябыштырырга тәкъдим итү. Берничә әйбер ябыштырганны мактау.Төсләрен һәм формасын сорау. |

**Январь**

| | | |
|---|---|---|
| Тема: | **2** нче атна<br><br>**Матур салфетка** | **4** нче атна<br><br>**Кар бабай** |
| Максат: | Квадрат формасындагы кәгазьдә почмакларда һәм уртада бер төстәге зур түгәрәкләр, ә һәр якның уртасында башка төстәге кечкенә түгәрәкләр урнаштырып бизәк төзергә өйрәтү. | Балаларны түгәрәк формадагы әйберләр һәм аларны зурлыгы буенча аера белүләрен ныгыту. Зурлыгы буенча өлешләрне дөрес урнаштырырга өйрәтү. Пөхтә итеп ябыштыру. |
| Балалар эшчәнле-генең төре | Бүген салфетка бизәячәкләрен әйтү.Салфет үрнәкләрен карау: ничек бизәлүен сорау. Фигураларның урна- шу тәртибен ачыклау һәм ябыштырырга тәкъдим итү. | Балалар белән кар бабайны әвәләүне искә төшерү: кар бабайны төзү тәртибен ачыклау. Өлешләрнең формасын һәм зурлыгын сорау. Өлешнең кайсыннан ябыштыра башлауны билгелү, аннан кайсын? Эшләрне бергәләп карау. |

**Февраль**

| | | |
|---|---|---|
| Тема: | **2** нче атна<br><br>**Түгәрәктә бизәк** | **4** нче атна<br><br>**Әниемә, әбиемә бүләккә чәчәкләр** |
| Максат: | Түгәрәктә бизәк төзәргә өйрәтү. Бизәкләрне бер тәртиптә төзергә өйрәтү. Форманы тулысынча җилем белән сөртүне ныгыту. Мөстәкыйльлелекне үстерү. | Детальләрдән сүрәт төзергә өйрәтү.<br><br>Матур әйбер ясарга теләк тудыру.<br><br>Эстетик кабул итүне үстерү. |
| Балалар эшчәнле-генең төре | Түгәрәктәге бизәк үрнәкләре карау:бизәкләрнең түгәрәк кырыйларында урнашуына, фигураларның зурлыгы буенча чиратлашуына игътибар итү. Ничек урнаштыруны күрсәтү. | Әниләргә матур рәсем ясарга тәкъдим итү. Түгәрәк өлешләрдән ничек итеп чәчәк төзергә икәнен балалардан сорау. Чәчәкләрнең таҗларын урнаштыруны күрсәтү. Матур чәчәкләр белән бергәләп соклану. |

**Март**

| Тема: | **2** нче атна<br><br>**Флаглар** | **4** нче атна<br><br>**Салфетка** |
|---|---|---|
| Максат: | 2 өлештән торган турыпочмак формасындагы әйбер сүрәтен төзеп ябыштырырга өйрәтү. Төсләрне аера, дөрес атый белүләрен ныгыту. Җилем белән пөхтә итеп эшли белү, форманы тулысынча җилем белән буяу. | Түгәрәк, квадратлардан квадрат формасындагы салфеткада бизәк төзергә өйрәтү. Ритм тоемлавын үстерү. Өлешләрне пөхтә итеп ябыштыру. |
| Балалар эшчәнле-генең төре | Балалар белән флаглар карау: өлеш-ләрен, формасын сорау. Флагның таягын кайсы яктан (уң) ябыштырырга кирәклеген ачыклау. Дөрес ябыштыру алымнарын куллануга игътибар итү. Тиз эшләгән балага тагын 1-не ябыштырырга тәкъдим итү. Әзер флагларны тактага кую. | Балалар белән әзер салфетка үрнәк-ләре карау:бизәк нинди фигуралардан төзелүен атау. Салфеткага өлешләрне урнаштырырга һәм ябыштырырга тәкъдим итү. Йомгаклау: салфеткаларның бизәкләрен карау, төсләрен атау. |

**Апрель**

| Тема: | **2** нче атна<br><br>**Сыерчык оясы** | **4** нче атна<br><br>**Тиздән бәйрәм җитә** |
|---|---|---|
| Максат: | Берничә өлештән торган предметларны сүрәтләргә, өлешнең форма-сын (түгәрәк, турыпочмаклы, өчпочмаклы) билгеләргә өйрәтү.Түгәрәк, квадрат, өчпочмак формасын кулланып сыерчык оясын ясарга өйрәтү. | Әзер фигуралардан билгеле бер эчтәлектәге композиция төзергә, флагчык һәм шарларга үзлектән урын табырга, сүрәт өлешләрен уртадан алып җилем белән буярга өйрәтү. Эстетик күзаллауны үстерү. |
| Балалар эшчәнле-генең төре | Шигырь уку. Сыерчык оясы нинди өлештән алар нинди формада икәнен искә төшерү. Әзер геометрик фигуралар<br><br>дан сыерчык оясы ябыштырырга тәкъдим итү. Йомгаклау: сары (яшел,..) стеналы сыерчык оясын күрсәтергә тәкъдим итү. | Бәйрәм турында сүрәт ясарга тәкъдим итү. Флаглар, шарлар ябыштырырга тәкъдим итү. Баштан флаглар, аннары шарлар ябыштырырга киңәш итү. Композициянең төрлелеген билгеләү. |

**Май**

| Тема: | **2** нче атна<br><br>**Чирәмдәге чебиләр** | **4**нче атна<br><br>**Йорт** |
|---|---|---|
| Максат: | Кәгазь битендә ирекле рәвештә урнаштырып, берничә предметтан торган композиция төзергә өйрәтү. Пөхтә итеп | Билгеле бер тәртиптә, берничә өлештән төзергә өйрәтү. Геометрик фигуралар (квадрат, турыпочмак, өчпочмак) |

| | | |
|---|---|---|
| | ябыштыруны ныгыту. | турындагы белемнәрен ныгыту. |
| Балалар эшчәнле-генең төре | “Чирәмдәге чебиләр” рәсемен карау. Бергәләп шундый сүрәт ясарга тәкъдим итү. Чебиләрне ябыштыру алымын ачыклау: күзләрен, томшык, аякларны кәгазь кисәген өзеп алып ябыштырырга өйрәтү. | Төзелеш җиһазларыннан төзелгән йортны карау. Йортның өлешләрен аеру, формасын ачыклау. Эш тәртибен, матур итеп кәгазь битенә пөхтә итеп ябыштыруны искә төшерү. |

**Музыка**

| **Сентябрь. Тема:“Көз”** | | | |
|---|---|---|---|
| | **Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлары** | **Музыкаль репертуар** |
| “Физик үсеш”, “Социаль-коммуникатив үсеш”өлкәләре белән интегральләштерү. | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| | **1. Музыка тыңлау.** *а) Музыка әсәрен кабул итү.* | Татар халык музыкасы һәм татар композиторларының музыкасына уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. Төрле характердагы музыкаль әсәрләрне тыңлау теләге булдыру. | “Әпипә”, т.х.к., Ю. Виноградов эшк.; “Көз”, Р.Еникеева муз.; “Прогулка”, В. Волков муз.; “Дождик”, Н. Любарский муз. |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Музыкада аваз югарылыгын ишетергә өйрәтү. | “Кошлар һәм кошчыклар”. |
| | **2. Җырлау.** *а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Җырлау күнекмәләрен үстерү. | “Әлли – бәлли, бәү”, т.х.бишек җыры, “Лю – лю – бай”, рус халык бишек җыры. |
| | *б) Җырлар.* | Балаларны җырлауга, кушылып җырлауга, җырларны игътибар белән тыңлауга омтылышларын активлаштыру. | “Көз килде”, Л. Шиһабетдинова муз., “Петушок”, “Ладушки”, р.х.җ. |
| | *в)Җыр иҗаты.* | Тыныч һәм күңелле көйләрне үрнәк буенча иҗат итү күнекмәләре формалаштыру. | “Әлли – бәлли”, т.х.к., Ф. Җәләлетдинова эшк. |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.** | Хәрәкәтләрне музыкага, ритмына, темпына, характерына туры китереп башкарырга өйрәтү. | “Чәбәкәй”, Р.Ахиярова муз.; “Марш”, Э. Парлов муз.; “Кто хочет побегать?”, лит.х.к.; Л. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *а) Уен күнегүләре* | | Вишкарёва эшк.; Погуляем”, Е. Тиличеева муз. |
| | *б) Этюд – драматизацияләр.* | Хәрәкәтләрне мөстәкыйль рәвештә башларга һәм тәмамларга өйрәтү. | “Самолёт”, Р. Зарипов муз. |
| | *в) Уеннар.* | Тирә - юньдә ориентлаша белү күнекмәләре формалаштыру. | “Яңгыр”, Р.Гатина муз., “Мячи”, Т.Ломова муз. |
| | *г) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Хәрәкәтләрне музыка ритмына, темпына, характерына туры китереп предметлар белән башкара алу күнекмәләрен үстерү.<br>Бию хәрәкәтләрен мөстәкыйль рәвештә башларга һәм тәмамларга өйрәтү. Түгәрәктә дөрес итеп атларга, яфраклар тотып биергә өйрәтү.<br>Татар биюләренә хас булган гади хәрәкәтләр белән таныштыру. | “Яфраклар бәйрәме”, Р. Еникеева муз.; “По улице мостовой», р.х.к.,Г.Фрид эшк.; “Гөмбәләр биюе”, Г.Гыйләҗетдинова муз. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Бию көйләренә мөстәкыйль рәвештә бию хәрәкәтләре башкарырга дәртләндерү. | “Бию”, т.х.к., Р. Зарипов эшк. |
| | **II.Мөстәкый йль сәнгать эшчәнлеге** | Бәрмә музыка уен кораллары белән таныштыру. | Кыңгырау, бубен, металлофон, барабан, шылтыравык, өчпочмак. |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | Музыка астында предметлар белән (көзге яфраклар, кулъяулыклар, шалтыравыклар) мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итүләрен формалаштыру. | |
| | | Балаларның активлыкларын үстерү, аларда шатлык хисләре уяту. | “Әбинең ишегалдында”. Тематик чара. |

| **Октябрь. Тема:“Мин һәм минем гаиләм”** | | | |
|---|---|---|---|
| | **Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлар** | **Музыкаль репертуар** |
| “Физик үсеш”, “Социаль- | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| | **1. Музыка тыңлау.**<br>*а) Музыка әсәрен* | Балаларны музыкаль әсәрне ахырына кадәр тыңлврга күнектерү.Әсәрнең эчтәлеген, характерын аңларга өйрәнү. | “Көзге вальс”, Ф. Шәймәрданова муз.; “Көзге яңгыр”, Р. Латыйпов муз.; “Грустный дождик”, Д. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *кабул итү.* | | Кабалевский муз. |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Музыкада ритмны тою сәләтен үстерү. | “Яңгыр ничек ява?”. |
| | **2. Җырлау.** *а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Җырлау күнекмәләрен үстерү. | “Сәгать”, Г. Гыйләҗетдинова |
| | *б) Җырлар.* | Балаларны җырлауга, кушылып җырлауга, җырларны игътибар белән тыңлауга омтылышларын активлаштыру. | “Көз”, М.Әндәрҗанова муз.; “Көз һәм балалар җыры”, Г. Гәрәева муз.; “Әтәчкәй”, Р. Гыйләҗева муз.; “Осенняя песенка”, Ан. Александров муз. |
| | *в)Җыр иҗаты.* | Тыныч һәм күңелле көйләрне үрнәк буенча иҗат итү күнекмәләре формалаштыру. | “Алма бирәм”, С. Гыйльфан сүз. |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.** *а) Уен күнегүләре* | Төп хәрәкәтләрне (йөрү, йөгерү) башкару күнекмәләрен камилләштерү. Күмәкләп һәм аерым – аерым марш атларга, җиңелчә йөгерергә өйрәтү. | “Марш”, Л. Шиһабетдинова муз.” “Йөгердек”, А. Монасыйпов муз. (“Этюд”; “Гуляем и пляшем”, М. Раухвергер муз. |
| | *б) Этюд – драматизацияләр.* | Кошлар образын тәэсирле итеп гәүдәләндерергә өйрәтү. | “Птички летают”, А. Серов муз. |
| | *в) Уеннар.* | Тирә - юньдә ориентлаша белү күнекмәләре формалаштыру. Җәнлек образын тәэсирле итеп гәүдәләндерергә өйрәнү.<br>Предметлар белән кызыклы һәм мавыктыргыч итеп уйнарга өйрәтү. | “Аю баласы”, Ф. Әбүбәкеров муз.; “Туп – туп, тубыбыз”, Л. Шиһабетдинова муз.; “Игра с погремушками”, р.х.к. , А. Быканов эшк. |
| | *г) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Хәрәкәтләрне музыка ритмына, темпына, характерына туры китереп предметлар белән башкара алу күнекмәләрен үстерү.<br>Бию хәрәкәтләрен мөстәкыйль рәвештә башларга һәм тәмамларга өйрәтү. | “Көз һәм балалар җыры”, Г. Гәрәева муз.; “Яфраклар белән бию”, Т. Вафина муз.; “Полянка”, р.х.к., Г. Фрид эшк.; “Воробушки”, венгр.х.к. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Бию көйләренә мөстәкыйль рәвештә бию хәрәкәтләре башкарырга дәртләндерү. | “Куяннар биюе”, Л. Хисмәтуллина муз. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *е) Бәрмә музыка уен коралларында уйнау.* | Балаларны музыка уен коралларында иң гади кушылып уйнау күнекмәләре булдыру. | “Бәллү”, Р. Ахиярова муз. |
| | **II.Мөстәкыйль сәнгать эшчәнлеге** | Музыка астында предметлар белән (күзге яфраклар, кулъяулыклар, шалтыравыклар) мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итүләрен формалаштыру. | |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | Балаларның активлыкларын үстерү, аларда шатлык хисләре уяту. | “Кошлар ишегалдында”. Курчак театры. |

| **Ноябрь. Тема:“Минем йортым, минем шәһәрем”** | | | |
|---|---|---|---|
| | **Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлары** | **Музыкаль репертуар** |
| “Физик үсеш”, “Социаль-коммуникатив үсеш”өлкәләре белән интегральләштерү. | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| | **2. Музыка тыңлау.** *а) Музыка әсәрен кабул итү.* | Өч музыкаль жанр белән (җыр, бию, марш) таныштыру. Музыканың характерын аңлау, аңа җавап хисләре тәрбияләү. | “Сүзсез җыр”, т.х.к., А. Вәлиуллина эшк; “Марш”, И. Шәмсетдинов муз.; “Песи”, т.х.к., М. Мозаффаров муз.; “Ласковая песенка”, М. Раухвергер муз.; “Плясовая”, р.х.к. |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Музыкада аваз югарылыгын ишетергә өйрәтү. | “Безгә кунаклар килгән”. |
| | **2. Җырлау.** *а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Җырлау күнекмәләрен үстерү. | “Су”, Ф. Җәләлетдинова муз. |
| | *б) Җырлар.* | . Җырны бер темпта, сүзләрне ачык һәм аңлаешлы әйтеп, көйнең характерына туры китереп җырларга өйрәтү. | “Тек – тек”, Т. Вафина муз.; “Зайчик”, р.х.к., Н. Лобачёв эшк.; “Зима”, В. Карасева муз. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *в)Җыр иҗаты.* | Күңелле көйне үрнәк буенча иҗат итергә өйрәтү. | “Уф, ардык!”, С.Гыйльфан сүз. |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.** *а) Уен күнегүләре* | Төп хәрәкәтләрне (йөрү, йөгерү) башкару күнекмәләрен камилләштерү. Ике кисәкле музыкага һәм яңгырау көченә карап хәрәкәт итәргә өйрәтү. | “Ай, матур гөл генә”, т.х.к., Р. Еникеева эшк. “Куллар өчен күнегү”, Л. Хисмәтуллина муз. “Пружинка”, р.х.к., Т. Ломова эшк. |
| | *б) Этюд – драматизациялэр.* | Образны тәэсирле һәм хисле итеп гәүдәләндерергә өйрәтү. | “Мышки”, Н. Сушен муз. |
| | *в) Уеннар.* | Тирә - юньдә ориентлаша белү күнекмәләре формалаштыру. Музыка астында күңелле итеп уйнарга өйрәтү. | “Качышлы”, т.х.к.; Ф.Җәләлетдинова эшк.; “Кошка и котята”, В. Витлин муз. |
| | *г) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Хәрәкәтләрне музыка ритмына, темпына, характерына туры китереп предметлар белән башкара алу күнекмәләрен үстерү. Бию хәрәкәтләрен мөстәкыйль рәвештә башларга һәм тәмамларга өйрәтү. | “Бию”, т.х.к.; Л. Шиһабетдинова эшк. “Пляска с листочками”, А. Филиппенко муз. “Фонарьлар”, Ф. Шәймәрданова муз. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Бию көйләренә мөстәкыйль рәвештә бию хәрәкәтләре башкарырга дәртләндерү. | “Парлы бию”,т.х.к. Л. Шиһабетдинова эшк. |
| | *е) Бәрмә музыка уен коралларында уйнау.* | Бәрмә музыка уен коралларында иң гади кушылып уйнау күнекмәләре булдыру. | “Әлли – бәлли”, Р. Ахиярова муз. |
| | **II.Мөстәкыйль сәнгать эшчәнлеге** | Бәрмә музыка уен коралларында (кыңгырау, бубен, металлофон, барабан, шылтыравык, өчпочмак) уйнауларын куәтләү, хуплау. | |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | Балаларның активлыкларын үстерү, аларда кызыксыну уяту. | “Яшелчә бакчасында”, Тематик чара. “Әнием, кадерлем!”. Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары концерты. |

**Декабрь. Тема:“Яңа ел бәйрәме”**

| | Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы | Тәрбия һәм белем бирү бурычлары | Музыкаль репертуар |
|---|---|---|---|
| “Физик үсеш”, “Социаль-коммуникатив үсеш”өлкәләре белән интегральләштерү. | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| | **3. Музыка тыңлау.** *а) Музыка әсәрен кабул итү.* | Балаларны контраст характердагы музыка тыңларга өйрәтү. Музыканың характерын аңлау, аңа җавап хисләре тәрбияләү. | Бишек җыры”, З. Хәбибуллин муз.; “Шаян кыз”, Н. Җиһанов муз.; “Усал малай”, Р. Зарипов муз.; “Бию”, А. Вәлиуллин муз.;”Пляска Петрушки”, М. Раухвергер муз. |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Ритмны тою сәләтен үстерү. | “Курчак нишли?” |
| | **2. Җырлау.** *а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Җырлау күнекмәләрен үстерү. | “Чәбәк – чәбәк”, Н. Бакиева эшк. |
| | *б) Җырлар.* | . Җырны бер темпта, сүзләрне ачык һәм аңлаешлы әйтеп, көйнең характерына туры китереп җырларга өйрәтү. | “Чыршыкай”, М. Бикбова муз.; “Кар кызы, кил безгә”, Ф. Шәймәрданова муз.; |
| | *в)Җыр иҗаты.* | Күңелле көйне үрнәк буенча иҗат итергә өйрәтү. | “Тукран”, Н.Бакиева муз. |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.** *а) Уен күнегүләре* | Музыканың характерына туры китереп атларга, йөгерергә өйрәтү. Хәрәкәтләрне музыка башында башлп музыка ахырында тәмамлауны формалаштыру. | “Марш”, Ә. Шәрәфиев муз.; “Атта”, Ф. әхмәтов муз.; |
| | *б) Этюд – драматизацияләр.* | Мөстәкыйль рәвештә йөрүдән йөгерүгә күчергә өйрәтү. | “Күк күгәрчен”, т.х.к., М. Мозаффаров эшк. |
| | *в) Уеннар.* | Тирә - юньдә ориентлаша белү күнекмәләре формалаштыру. | “Кар бөртекләре”, Р. Гатина муз.; “Ловишки”, Й. Гайдн муз. |
| | *г) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Балаларны шылтыравыклар белән музыкага кушылып уйнарга өйрәтү. Җырлардагы хәрәкәтләрне төгәл, | “Шылтыравыклар белән уен”, Г. Гыйләҗетдинова муз.; “Кыш бабай белән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | ритмлы итеп башкарырга өйрәтү. Биюдәге образны тәэсирле һәм хисле итеп башкарырга өйрәтү. | күмәк җыр", "Кар кызы, кил безгә", Ф. Шәймәрданова муз. "Кар бөртекләре оча", Р. Гыйләҗева муз. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Бию көйләренә мөстәкыйль рәвештә бию хәрәкәтләре башкарырга дәртләндерү. | "Парлы бию",т.х.к. Л. Шиһабетдинова эшк. |
| | *е) Бәрмә музыка уен коралларында уйнау.* | Бәрмә музыка уен коралларында иң гади кушылып уйнау күнекмәләре булдыру. | "Әпипә", т.х.к. |
| | **II.Мөстәкыйль сәнгать эшчәнлеге** | Бәрмә музыка уен коралларында (кыңгырау, бубен, металлофон, барабан, шылтыравык, өчпочмак) уйнауларын куәтләү, хуплау. | |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | Балаларда шатлык хисләре уяту. | "Мәче белән аю", т.х.к. Курчак театры. "Чыршы бәйрәме". |
| **Гыйнвар. Тема:"Кыш"** | | | |
| | **Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлары** | **Музыкаль репертуар** |
| "Физик үсеш", "Социаль-коммуникатив үсеш"өлкәләре белән интегральләштерү. | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| | **4. Музыка тыңлау.** *а) Музыка әсәрен кабул итү.* | Балаларда төрле характердагы музыкаль әсәрләр тыңлау теләге булдыру. Җырның эчтәлеген аңлый, музыканың характерын аера белергә өйрәтү. | "Кыш бабай җыры", Л. Шиһабетдинова муз.; ""Буран", М. Мозаффаров муз.; "Курчаклар маршы", Р. Еникеев муз.; "Плясовая", (р.х.к.). |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Тембрны аера белү һәм динамик төсмерләрне ишетү сәләтен үстерү. | "Нәрсәдә уйныйм?" |
| | **2. Җырлау.** *а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Көйне чиста интонация белән көйләргә күнектерү. | "Барабан", Н. Бакиева муз. |
| | *б) Җырлар.* | Музыкаль инструментка кушылып дәртле, моңлы, сузынкы җырларны ягымлы итеп, көчәнмичә җырларга өйрәтү. | "Бишек җыры", т.х.ж., Р. Тимершина эшк.; "Ап-ак карлар", Г.Гәрәева муз. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *в)Жыр ижаты.* | Бала үзенең һәм башкаларның исемен көйли алуларын формалаштыру. | “Исемең ничек?”. |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.** *а) Уен күнегүләре* | Ике кисәкле музыкага, яңгырау көченә карап хәрәкәт итәргә өйрәтү. | “Күңелле”, А. Монасыйпов муз.; “Марш и бег”, Ан. Александров муз. |
| | *б) Этюд – драматизацияләр.* | Сәхнәләштерелгән гади күренешләрдә, уеннарда төле образларны тәэсирле, хисле итеп башкарырга өйрәтү. | “Куяннар һәм төлке, Ф. Шәймәрданова муз. |
| | *в) Уеннар.* | Уенның эчтәлеген аңлап, хисле итеп уйнарга өйрәтү. | “Бу куянга ни булган?, Л. Хисмәтуллина муз.; “Цыплята”, А. Филиппенко муз. |
| | *г) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Бию хәрәкәтләрен музыка ритмына, темпына, характерына туры китереп башкарырга өйрәтү. | “Курчаклар белән бию”, Ф. Шәймәрданова муз.; “Потанцуем вместе”, р.х.к., Н. Метлов эшк. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Төрле образдагы хәрәкәтләрне тәэсирле һәм хисле итеп башкара белүләрендә дәртләндерү. | “Апа белән без дуслар”, Л, Шиһабетдинова муз.; “Медведь”, М. Раухвергер муз. |
| | *е) Бәрмә музыка уен коралларында уйнау.* | Бәрмә музыка уен коралларында (кыңгырау, бубен, металлофон, барабан, шылтыравык, өчпочмак) уйнауларын куәтләү, хуплау. | “Әнисә”.т.х.к. |
| | **II.Мөстәкыйль сәнгать эшчәнлеге** | Таныш җырларны җырлауларын, музыкаль уенчыкларда уйнауларын хуплау | |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | Балаларда шатлык хисләре уяту. | “Кыш”. Курчаклар өчен концерт. |

| **Февраль. Тема:“Ватанны саклаучылар көне”** | | | |
|---|---|---|---|
| | **Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлары** | **Музыкаль репертуар** |
| “Физик | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | үстерү. | |
| | **5. Музыка тыңлау.** *а) Музыка әсәрен кабул итү.* | Музыканы тыңлый, танып белү, исемен атый белүләрен ныгыту. Музыкаль әсәрнең характерын ачыклый белүләрен формалаштыру. Ике өлештән торган пьесаларны аера белергә өйрәтү. | “Содат булдым”, Р, Еникеев муз.; “Авыл көе”,(т.х.к.), А. Вәлиуллин эшк.; “Өммегөлсем”,(т.х.к.), Ф. Фәизова эшк.; “Солдатский марш”, Р. Шуман муз. |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Тембрны аера белү һәм динамик төсмерләрне ишетү сәләтен үстерү. | “Кемнең өе?”. |
| | **2. Җырлау.** *а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Чиста интонация белән көйләүдә күнектерү. | “Солнышко – вёрдышко”, - юаткыч. |
| | *б) Җырлар.* | Җиңел аваз белән, көчәнмичә, кереш өлештән соң төгәл башлап, ахырында җырны тәмамлап җырлый белүләрен формалаштыру. | “Әнием”, Р. Гыйләҗева муз.; “Әбекәй”, Т. Вафина муз.; “Мы – солдаты”, Ю. Слонов муз. |
| | *в)Җыр иҗаты.* | Балаларны җыр иҗатына өндәү. Олылыр ярдәмендә дәртле, күңелле көй иҗат итүләрен формалаштыру. | “Куян һәм курчак ничек итеп бии?”. |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.** *а) Уен күнегүләре* | Музыканың башына һәм ахырына игътибар итеп, йөрү һәм йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. | “Бию”, Җ. Фәйзи муз.; “Топатушки”, М. Раухвергер муз. |
| | *б) Этюд – драматизацияләр.* | Төрле образларның характерын тасвирлаган хәрәкәтләрне башкару мөмкинлекләрен үстерү. | “Аю баласы”, Ә. Шәрәфиев муз.; “Самолёт”, Е Тиличеева муз. |
| | *в) Уеннар.* | Уенның эчтәлеген аңлап, күңелле итеп башкарырга өйрәтү. | “Качышлы уен”, В. Вәлиева муз.; “Игра с цветными флажками”, р.х.к. |
| | *г) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Татар халык бию хәрәкәтләре белән танышуны дәвам итү һәм аларны башкару күнекмәләре формалаштыру. | “Төсле яулыклар”, т.х.к., Р Гатина эшк.; “Куяннар бииләр”, М. Әндәрҗанова муз. |
| | *д) Биюле уен иҗатын* | | “Весёлые ножки”, р.х.к., В. Агафонников эшк. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *үстерү* | | |
| | *е) Бәрмә музыка уен коралларында уйнау.* | Бәрмә музыка уен коралларында (кыңгырау, бубен, металлофон, барабан, шылтыравык, өчпочмак) уйнауларын куәтләү, хуплау. | “Шома бас”, т.х.к. |
| | **II.Мөстәкыйль сәнгать эшчәнлеге** | Таныш җырларны җырлауларын, музыкаль уенчыкларда уйнауларын хуплау. | |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | | “Кем нәрсә ярата?”.Курчак театры.(т.х.ә.) “ Әтием – горурлыгым”. Музыкаль – спорт чарасы. |

| **Март. Тема:“ Халыкларның гореф гадәтләре, милли йолалары”** | | | |
|---|---|---|---|
| | **Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлары** | **Музыкаль репертуар** |
| “Физик үсеш”, “Социаль-коммуникатив үсеш”әлкәләре белән интегральләштерү. | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| | **6. Музыка тыңлау.** *а) Музыка әсәрен кабул итү.* | Музыкага эмоциональ мөнәсәбәт тәрбияләү. Контраст характердагы әсәрләр белән таныштыруны дәвам итү. | "Тамчылар бии". А. Батыршин муз.; "Яз", Р. Ахиярова муз.; "Куян биюе", "Аю", Р.Еникеев муз.; "Яңгыр", Л. Хисмәтуллина муз. |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Жанрны аера белү һәм музыкаль хәтерләрен үстерү. | "Тылсымлы капчык". |
| | **2. Җырлау.** *а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Чиста интонация белән көйләүдә күнектерү. | "Яңгыр, яу” (эндәшү). |
| | *б) Җырлар.* | Музыкаль инструментка кушылып җырларга, җырларны танып белергә өйрәтү. Бер темпта ашыкмыйча һәм артта калышмыйча җырларга өйрәтү. | "Яз килә", Т. Вафина муз.; "Йоклыйсым килә", М. Шәмсетдинова муз.; "Зима прошла", Н. Метлов муз. |
| | *в)Җыр иҗаты.* | Бишек җырларын "бәү - бәү" сүзләренә җырлап бетерергә өйрәтү. | "Әлли - бәлли", т.х.к. |
| | **3. Музыкаль** | Ике өлештән торган музыкага | "Без бердәм атлыйбыз", Н. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | – **ритмик хәрәкәтләр.** *а) Уен күнегүләре* | кушылып, характерына туры китереп хәрәкәтләрне үзгәртергә өйрәтү. | Бакиева муз.; "Лошадка", М. Симанский муз. |
| | *б) Этюд – драматизацияләр.* | Төрле җәнлек, кошлар кыяфәтен күрсәткән хәрәкәтләр ясауны өйрәтүне дәвам итү. | "Кошлар килде", З. Хәбибуллин муз.; "Жуки", венгр.х.к., Л. Вишкарёв эшк. |
| | *в) Уеннар.* | Төрле җәнлек, кошлар кыяфәтен күрсәткән хәрәкәтләр ясауны өйрәтүне дәвам итү. | "Песи һәм чыпчыклар", М. Әндәрҗанова муз. |
| | *г) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Музыканың башын һәм ахырын дөрес билгеләп, мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итәргә өйрәтү. | "Нәниләр", Ф. Шәймәрданова муз.; "Яз җитә", Җ. Фәйзи муз. "Помирились", Т.Вилькорейская муз. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Җырны эчтәлеге буенча сәхнәләштерергә, тиешле хәрәкәтләр ясарга дәртләндерү. | "Сөмбел", С. Садыйкова муз. |
